КАДЕРЛЕ ЙОМГАК

Быел кош-кортлы булу кыйммәтегә төшәчәк?

> 5

МОГҖИЗА КӨТКӘНДӘ

Бала таба алмаган гаиләләр бу хыялыннан барыбер баш тартмый

> 16

РИНАТ ӘЮПОВ:

«Нигездән бер генә кирпечне тартып ал – ул ишеләчәк»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 33 (29193) | Җомга | 15 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

mchs.gov.ru

ЯЗГЫ (СА)ТАШУ

КАРЛЫ КЫШТАН СОҢ КИЛГӘН ЯЗДАН НӘРСӘ КӨТӘРГӘ?

Җиһанда – яз! Көннәр аяз, күктә кояш елмая, йорт кыекларыннан тып та тып тамчылар тама. Быелгы кебек салкын карлы кышта язны аеруча да сагындык. Тик мартны күбрәк ваклаган саен күңелдә шом арта. Кыш көне ишеп яуган кар хәвеф-хәтәр алып килмәсме? Быелгы яздан нәрсә көтәргә? «ВТ» хәбәрчесе бу хакта белгечләр белән сөйләште һәм язгы ташу чорында су басучы авылларда яшәүчеләрнең хәлен белеште.

> 6–7

Ишетми калмагыз

Ел башыннан Социаль фондның Татарстандагы бүлеге 42,5 мең гаиләдәге 190 меңнән артык балага бердәм пособие билгеләде. Бу максатларга фонд якынча 4,2 миллиард сум акча җибәрде.
Исегезгә төшерәбез: бердәм пособие исәп-хисап чорында гаиләнең һәр әгъзасына җан башына уртача керем яшәү минимумы күләменнән артмаса билгеләнә. Татарстанда әлеге күрсәткеч 12741 сумны тәшкил итә. Пособие бу сумманың 50%, 75% яки 100% күләмендә булырга мөмкин. Моннан тыш, гаилә күчемле һәм күчемсез милек таләпләре кысасына да сыешырга тиеш.

Балаларга яхшы белем бирү һәм сыйфатлы итеп дәвалану өчен Татарстаннан читкә китүнең мәгънәсе юк. «ПромРейтинг» агентлыгы уздырган сораштыру барышында республикада яшәүчеләрнең 84,5 проценты шундый фикер белдергән.
Алардан Татарстанда балалар өчен булдырылган шартлар турында сорашканнар. Җавап бирүчеләрнең 78 проценты әйтүенчә, аларның бала чагы белән чагыштырганда, хәзер шартлар яхшырак. Республикадагы хәлләрдән иң канәгать кешеләрнең пенсия яшендәге ир-атлар булуы ачыкланган.

Татарстанда язгы чистарыну көннәре билгеле. 1 апрельдән 31 майга кадәр санитария-экология икеайлыгы уздыру турында боерыкны Премьер-министр Алексей Песошин имзалаган.
Документка караганда, муниципалитетларның башкарма комитетлары 22 мартка кадәр территорияләрне чистарту планнарын эшләп расларга тиеш. Чистарту-җыештыру эшләрен җайга салу өчен оператив штаблар булдырылачак. Икеайлыкта барлык авыл-шәһәрләр экология, санитария-эпидемиология таләпләренә туры килердәй дәрәҗәдә чистартылырга тиеш.

Татарстанга көньяк-көнчыгыштан антициклон үтеп кергән. Шуңа күрә явым-төшемсез болытлы һава күзәтелә.
Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, якындагы көннәрдә – 16–17 мартта республика антициклон йогынтысында калып, һава торышында сизелерлек үзгәрешләр булмаячак. Явым-төшем көтелми. Көндез термометрның терекөмеш баганасы 0...+6 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнге сәгатьләрдә –4...–9, уйсу урыннарда –14 градус. Шул ук вакытта тәүлеклек уртача температура нормадан 3–4 градуска артыграк булачак. Мондый һава торышы карның акрынлап кына эрүенә китерә.
Гидрометеоүзәкнең башлангыч мәгълүматларына караганда, киләсе атна башында – 18–19 мартта урыны белән аз гына кар явачак. Һава температурасы үзгәрмәячәк: көндез +1...+6, төнлә –3...–8, урыны белән –11 градус тәшкил итәчәк.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Район хастаханәсендә эшләүче татар телен белүче табиблар халатларына «Татарча беләм» билгеләре беркетеп йөри башлады. Мондый тәкъдим белән Казанның хокук яклаучысы Татарстан Рәисе һәм республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгына мөрәҗәгать иткән иде. Бу идеяне Түбән Кама үзәк район хастаханәсе баш табибы Руслан Вәлиев хуплады. Аның фикеренчә, бу яңалык пациентларга үз хәлләрен табибка тизрәк аңлатырга, ә табибларга кирәкле ярдәмне тиз арада күрсәтергә ярдәм итәчәк. (nkamsk-rt.ru)

Актаныш

Татар Суыксуы авылында «Агыйдел» кооперативының ярым әзер ит продукциясен җитештерү цехы ачылды. Әлеге кооператив җитештергән продукция авылда гына түгел, Чаллы, Казан кебек шәһәрләрдә дә тарала башлаган. Кооперативта атлар да асрыйлар. «Үзебезнең кырлардагы бодайдан икмәк пешерү, үзең карап үстергән маллардан хәләл продукция җитештерү районыбыз өчен бик зур әһәмияткә ия. Беренчедән, бу чагыштырмача очсыз, икенчедән, экологик чиста, өченчедән, ышанычлы», – диде цехны ачу тантанасына килгән Актаныш районы башлыгы Ленар Зарипов. («Актаныш-информ»)

Кукмара

Кукмара киез итек комбинатында «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» истәлек тактасы куелды. Комбинатка әлеге исем узган ел Татарстан Рәисе карары белән бирелде. «Фабриканың Җиңүгә керткән өлеше зур. Монда армия ихтыяҗлары өчен 1,5 миллионнан артык пар киез итек җитештерелгән. Фронтка фабрикадан 429 ир-ат китә, алар урынына хатын-кызлар, өлкәннәр һәм үсмерләр кала. Бөек Ватан сугышы вакытында тылда хезмәт куйган, һәрвакыт фабрика язмышы белән яшәгән кешеләргә рәхмәт», – ди комбинатның генераль директоры Ләлә Шәрипова. («Хезмәт даны»)

Питрәч

Ленино-Кокушкино авылында яшәүче Наталья Юрина бер ел элек «Особый-ЖеРебенок» адаптив ат спорты һәм иппотерапия үзәге ачкан, бу адымга аны сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикле булган кызы Меланья этәргән. Әлегә үзәк эшчәнлеген Казан ипподромында алып бара, язын Юриннар Ленино-Кокушкино авылындагы җир участокларында ат абзары төзергә планлаштыралар. «Без элек атларга битараф идек. Операция ясатканчы иппотерапия белән шөгыльләнергә кирәк дигән киңәш кенә фикерне үзгәртте», – ди Наталья ханым. («Алга»)

tatarstan.ru

САВАПЛЫ ЭШ

Яңа Тура авылы халкы өчен сөенче: Яшел Үзән районында яңа иман йорты ачылды. Ачылыш тантанасында Татарстан Рәисе дә катнашты.

Мәчет 250 урынга исәпләнгән. Биредә хатын-кызлар өчен аерым, ир-атларга аерым заллар бар. Шулай ук балалар белән дәресләр алып бару мөмкинлеге дә каралган. Аллаһ йортын төзү хәйриячеләр акчасына һәм Татарстан Рәисе каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды белән берлектә алып барылган.

Алга таба мәчет һәм якындагы территорияне төзекләндерү планлаштырыла. Биредә мәдрәсә, никах үзәге, кунакханә һәм балалар бакчасы ачылачак. Шулай ук спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыклары барлыкка киләчәк.

– Рамазан аенда шушындый шатлыклы вакыйга! Мәчет төзелешенә үз өлешен кертүчеләргә рәхмәтемне белдерәм. Бу – бик зур һәм рәхмәтле эш, – диде Татарстан Рәисе.

Яшел Үзән районы башлыгы Михаил Афанасьев, мәчет ачылышы Яңа Тура халкы өчен көтелгән вакыйга иде, ди.

– Мәчет уңышлы урында урнашкан. Бу территория әле үсәчәк. Янәшә олы юл төзелә. Якында гына сәнәгать паркы. Анда төрле милләт вәкилләре, җәмгысы 17 меңнән артык кеше эшли. Мәчет барысы өчен дә уртак йорт булыр дип ышанам, – диде район башлыгы.

Моннан тыш бу көнне республика Рәисе Татарстан митрополиты белән православие үсеше мәсьәләләре турында да сөйләште, Казан Богородица монастыренда булды. Аерым алганда, Рөстәм Миңнеханович Никола Тульский гыйбадәтханәсе бинасын, корпусларны, чиркәү-мәхәллә мәктәбе бинасын күрсәттеләр. Рөстәм Миңнеханович хәбәр итүләренчә, хәзерге вакытта әлеге объектларны тикшерү эшләре бара. Ул исә:

– Яңарту эшләре нинди чыгымнар таләп итәсен аңларга кирәк. Бу объектларны төзекләндерү – изге эш, – диде.

Сүз уңаеннан, Рәис үзенең «Телеграм» сәхифәсендә мөселманнар һәм православие вәкилләре өчен мөһим вакыйгалар турында искә төшерде.

– Мөселманнар өчен рамазан ае башланды, православие динен тотучыларның Бөек Посты башлана. Барыбыз да догаларыбызда үзебезгә һәм якыннарыбызга саулык, уртак Ватаныбызга тынычлык һәм иминлек телик! – дигән Рөстәм Миңнеханов.

Фикер

Ренат ВӘЛИУЛЛИН,
Татарстан Халыклары ассамблеясы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе:

– Динара һәм милләтара дуслыкның безнең республикада шундый дәрәҗәдә куелуы – Россия өчен үрнәк. Моны инде бер генә тапкыр мисал итеп китермәделәр. Татарстанда халыкларның үзара дус яшәве генә түгел, ярдәмләшеп яшәве – хәтта ки чит илләр өчен дә матур үрнәк. Иң мөһиме – үзара хөрмәт белән яшәү. Бу бит юктан бар була торган күренеш түгел. Моңа бик күп факторлар, шул исәптән тарихи сәбәпләр дә йогынты ясый. Бу территориянең электән дә күпмилләтле булуы һәм әлегәчә шул юлдан атлавын күрәбез. Татарстан җитәкчелеге алып барган сәясәте дә мөһим роль уйный. Һәрбер милләт үзенә игътибар барлыгын тоеп яши. Кечкенә йә зур милләт дигән төшенчә юк ул. Бар «милләт». Республикада барлык милләтләргә үсеш, матур тормыш алып бару өчен шартлар тудырылган.

ҖИҢЕЛӘЙТҮ САКЛАУ ТҮГЕЛ

Татарстандагы кибет киштәләреннән алып тикшерелгән азык-төлекнең өчтән бер өлеше сыйфатсыз дип табылган. Кулланучылар көне уңаеннан журналистлар белән очрашуда Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге җитәкчесе Розалия Арсланова әнә шулай дип белдерде.

– Без товарларны республика кибетләреннән ешерен сатып алучылар кебек сатып алабыз. Узган ел лабораторияләрдә 348 төр продукция тикшерелде. Кызганычка, 121 төрдәге товарның таләпләргә җавап бирмәве ачыкланды. Аларның барысы да кулланучылар кулына барып ирешкән иде инде, – диде ул.

Аның сүзләренчә, кибет киштәләреннән көндәлек тормышта кулланыла торган гап-гади ризыклар алынган. Ә кагыйдә бозу очраклары аеруча сөт продукциясенә кагылган. Шунысы игътибарга лаек: фальсификат дип табылган азык-төлекнең 94 проценты башка төбәкләрдән кертелгән.

– Шуннан соң без мәгълүматны барлык җаваплы органнарга тапшырабыз. Әйе, чаралар күренә, тик әлегә алар безне канәгатьләндерми. Булдыра алганча көрәшәбез, быел бу мәсьәләгә аеруча басым ясаячакбыз, – диде Розалия Арсланова.

Розалия Арсланова ясалма интеллектның тормышыбызга көннән-көн ныграк үтеп керүенә дә мисаллар китерде. Мондый шартларда кулланучылар хокукын саклау тагын да авырлаша.

– Киләчәк биш елда ясалма интеллект бик алга китәчәк. Бу, әлбәттә, бик яхшы, ләкин кулланучылар буларак без кем белән эш итүебезне белеп торырга тиешбез. Беренчедән, безнең арада нейрочелтәрне бик әйбәт аңламаучылар, интернеттан начар кулланучылар да бар. Шуңа күрә бу категория кешеләрне яклау өчен мөмкин булганча ачык итеп эшләү, бар кеше аңлаешлы кагыйдәләр булдыру кирәк. Икенчедән, ышанычлылык, мәгълүматларны таратмау мөһим. Өченчедән, җаваплылык. Менә шушы күзлектән чыгып, без кулланучылар хокукын закон белән ныгытмакчы булабыз. Кызганычка, әлегә нейрочелтәрләргә бәйле проблемалар бар, – диде җитәкче.

Әлегә нейрочелтәрләргә бәйле шикаятьләр кабул ителмәсә дә, көндәлек тормышта очрый торган проблемалар белән мөрәҗәгать итүчеләр саны кимеми. Узган ел кулланучылардан 2500дән артык мөрәҗәгать килгән, белгечләр төрле сораулар буенча 13000 консультация үткәргәннәр. Кешеләрне барыннан да бигрәк сәүдә, көнкүреш хезмәте күрсәтү, торак-коммуналь хезмәтләр, җәмәгать туклануы өлкәсенә кагылышлы мәсьәләләр борчый.

Зөһрә САДЫЙКОВА

НИХӘЛЛӘРДӘ ЯТАСЫЗ?

Сораштыру

Илшат НУРИЕВ, Арча районы башлыгы:
– Кәефләребез әйбәт. Халык сайлауга әзерләнә. Бүгеннән тавыш бирә башлыйбыз бит инде. Яз да әкренләп килсә, уңыш мул булыр дип көтәбез. Өметсез шайтан гына, диләр бит. Элек әбиләр, кар яуса, муллык ява, дип әйтә иде. Быел кар күп булуы сөендерә. Районыбызда хәлләр зарланырлык түгел. Тәүлегенә 240 тонна сөт сатып алабыз. Чәчүгә әзерлек бара. Ашламалар әзерлибез. Махсус хәрби операциядәге егетләрне дә онытмыйбыз. Гел ярдәм җибәреп торабыз. Район халкы бик актив. Сабалылардан өйрәнеп, коры аш әзерли башладык. Егетләргә 30дан артык мунча илттек инде. Алар сораган техникаларны да юнәтәбез. Бездә волонтерларның биш төркеме эшли. СВОдагы егетләрне кайгыртучан һәркемгә рәхмәттән башка сүз юк. Бер генә теләк – илләр тынычланып, егетләр исән-сау җиңеп кайтсын иде.

Рәмзия ӘХМӘДУЛЛИНА, бакчачы (Казан):
– Яз килгәне сизелә башлады. Күңелләр күтәрелеп китте. Мин язга үзгәрешләр белән керәм. Озак еллар эшләгән эш урынымны алыштырдым. Әкренләп яңасына өйрәнәм. Гел юлда әле бу арада. Өйгә сөенеп кайтып керәм. Барыбызны да янына җыя торган 3 айлык оныгым бар минем. Әнә шуңа да дөнья бөтенләй башкача хәзер. Ә инде үз йортыбыз белән яшәгәч, яз җитүгә, эшләр дә күбәя. Бакча эшләрен бик яратам. Үзем белгәннәрне социаль челтәрләрдә башкалар белән дә бүлешәм. Тиздән үземнең дусларымны җыеп бәйрәм уздырырга дип торам. Инде гыйнвар, февраль айларында ук помидор, борыч чәчтек. Шактый чәчәкләр дә утырттык. Үзем сынаган орлыкларны гына алам. Аларның да төрлесе бар. Барысын да белеп эшләргә кирәк.

Нурия САДЫЙКОВА, Яшел Үзән психоневрологик интернаты тәрбиячесе:
– Күп еллар авырулар белән эшләсәм дә, арымыйм. Шулар янына барсам, күңелем күтәрелеп кайта. Интернаттагылар да минем килүне көтеп тора. Әле менә 8 Март бәйрәме уңаеннан бездә тәрбияләнүче яшүсмерләрнең әниләрен чакырып бәйрәм уздырдык. 10 ана килде. Бик җылы, рәхәт очрашу булды. Бездә яшәүчеләрнең кайберләре янына әти-әнисе килеп йөри бит. Елга бер тапкыр бер айга өйләренә дә алып китеп торалар. Яшермим, бездәге авыруларны тәрбияләү өчен сабырлык кирәк. Ә миңа алар иягләшкән инде. Күз карашыннан да аңлашабыз. Сез – безнең икенче әни, диләр. Арада бик сәләтлеләре бар. Бииләр дә, җырлыйлар да. Бер егетебез бернинди белемсез уен коралларында уйный. Безнең диджей инде ул. Тик менә музыка аппаратурабыз ватылды. Төзәтеп тә булмый. Яңасын алырга мөмкинлек юк. Әллә ничә оешма җитәкчесенә, әллә ничә иганәчегә мөрәҗәгать итеп карадым. Тик, булышам, диючесе генә булмады. Бар өмет – рамазан аенда. Бәлки, шушы изге айда ярдәм итүче табылыр дип өметләнеп торам.

Альмир ЗЫЯТДИНОВ, Мамадыш районының Усали авылы җирлеге башлыгы:
– Авылда яз исе юк әле. Ичмасам, карга тавышы да ишетелми. Хәзер бит элеккеге кебек авыл урамнарында карга оялаган агач та табып булмый. Тупылларны, каеннарны кисеп бетердек. Кар да күп әле. Бу арада үлем-китем булды. Өч кешене җирләдек. Җирдә туң юк. Кар тиз эреп бетәр дип көтәбез инде. Халык, бәйрәм көткәндәй, сайлау көнен көтә. Авылны әйләнеп чыккан идем, түбән очтагылар да, без үзебез киләбез, диләр. Авыл кешесе мондый эшкә бик җаваплы карый. Шәһәрдә генә сайлау бертөрле уза бит ул. Авылларда бу көн чынлап та бәйрәмгә әйләнә. Кунаклар кайта, тәмле ризыклар әзерләнә. Тормышыбыз шөкер итәрлек. Кибетебез эшләп тора. Нинди генә зар булса да, аны шундук хәл итәбез. Җирлектәге халык белән аңлашып эшлибез.

Рөстәм ЗАКИРОВ, Татарстанның халык артисты:
– Күңелдә күптән яз инде. Төрле чараларга йөреп торам. Быел ураза тотмаска булдым. Үзенең сәбәпләре бар. Моңа кадәр калдырмый идем. Гаиләмдә тынычлык. Люция белән матур гына яшәп ятабыз. Балалар үзләренчә инде хәзер. Айрат, өч айга килешү төзеп, Согуд Гәрәбстанына күчте. Әлегә шунда саксофонист булып эшли. Миләүшә җырчы Ришат Төхвәтуллин концертларында чыгыш ясый башлады. Әле менә күптән түгел өчебез бергә «Балалы солянка»да катнаштык. Бөтен җаным-тәнем белән 13 апрельдә «Чулпан» мәдәният йортында узачак концертыма әзерләнәм. Анда Люция белән Миләүшә дә катнаша. «Пошалым чаналары»нда җиңгән берничә кеше дә чыгыш ясаячак. Быел бәйгенең географиясен киңәйттек бит. Сабадан да, Балтачтан да катнаштылар. Бик талантлы кешеләр бар. Киләсе бәйгедә кукмаралыларны да катнаштырырга дип торабыз. Талантлылар ел да табылып тора. Бу безне бик сөендерә.

Марина САПУРИНА, завод эшчесе (Алабуга):
– Бу көннәрдә мәрхүм кызым Венераның туган көне иде. Исән булса, 27 яше тулыр иде балама. Әбисе белән беркөнне иде туган көннәре. Каенанама 85 яшь тулды. Кызымның вафатына 5 ай булды инде. Баламны бик сагынам. Чит илдә яшәгәч, ул әле дә шунда кебек тә булып куя. Әмма гомеренең соңгы көннәрендә янәшәсендә булып, ничек азаплануын күргәч, аны югалтуымны да аңлыйм. Бу хәсрәт белән яшәү бик авыр. Әмма тормыш дәвам итә, бернишләп тә булмый. Улым, оныкларым өчен яшәргә кирәк. Бер генә теләгем: балам рәнҗеп ятмасын иде! Укыган догаларыбыз кабул булсын, дип телим.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Салкын

Кайчагында гайре табигый хәлләр аяк астында гына йөри икән ул. Яки баш очында. Көтмәгәндә, бер дә юктан туган сәерлекне шулай дип әйтәләр бугай.

Өлкән яшькә җитеп килгән ир белән хатын кышны авылдагы йортларына кайтып кышламакчы булалар. Җәйләре болай да шунда уза инде, җирен тырмаштырып, ихата-кураны карап, гомер уздыралар. Үзләре яшәгән шәһәргә бик якын түгел, шулай да ата-ана йортын юкка чыгарасылары килми. Бездә күп кеше үзен ата-бабага бурычлы дип саный бит инде, хәтта әнә шундый милекләрен ташлап китүне аларга хыянәт итү кебек кабул итә. Югыйсә якынрак берәр авылдан йорт сатып алып, шунда гомер үткәрсәләр, бу арзангаракка да төшәр, файдалырак та, уңайлырак та булыр иде. Болар да җәй буе кураларын ныгыталар, мунчаларын, сарайларын карыйлар. Бакчаларын да үги итмәскә тырышалар. Шуннан соң кышларга калалар.

Кыш салкын гына килә. Газ мичен гадәти кеше икеөч шкаласында тота, ә болар дүрткә-бишкә кадәр менгереп ягалар, чөнки өйләре салкын була. Йорт иске булса да, ташландык түгел, нигезләре ныгытылган, такта белән дә, профнастил дип аталган калай белән дә тышланган. Эчке яктан да җылытып эчләнгән. Тәрәзәләр яңартып эшләнгән, бернинди һава үткәрерлек түгел. Пар торбалары искерәк искелеген дә, тик алар һәрвакыт кызу, кул тидергесез. Нык итеп яккач, шулай булырга тиеш бит инде. Ә өйләре салкын.

Берничек тә башны җитәрлек түгел. Ир бер иртәдә начар төшләр күреп уяна да, юрган астыннан йорттагы салкын һавага чыккач, идәннәрне тоткалап карый – җылы, тик өйдә салкын һава йөргән кебек. Һәм башына сәер фикер килә. Болай булырга тиеш түгел бит инде, бу берәр төрле зәхмәт-фәлән түгел микән? Сәер фикерләр тиз зурая бит ул. Бераздан моңа да стеналардан, түшәмнәрдән салкын саркылган сыман тоела башлый.

Хуҗалары ташлап киткән йортлар турында бала йоннарын кабартырлык хәлләрне еш сөйлиләр бит инде. Үз авылларында гына да, хәтта күрше-тирәләрдә генә дә андый очраклар җитәрлек. Кемнәрнекендә төннәр буе ут янып чыга икән, кемнекендә сәер авазлар ишетелә. Шулай булгач, өеңә зәхмәт иялашмагандыр дип өздереп кенә әйтеп тә булмый.

Тиз генә әзерләнәләр дә Коръән укыталар. Табын коруның хәзер әллә ни мәшәкате юк. Ә ата-бабаларны искә алып, әрвахлар рухын сөендерү – үзе бер савап. Саваплы да, файдалы да мондый эшкә элегрәк тотынмаулары өчен үкенеп тә куялар.

Тик аның белән генә бетми. Өйдәге салкынлык барыбер дәвам итә. Җылы көннәрдә салкынның йомшагыгы керә, ачы суыкларда – кулга тисә, сынып төшәрлеге. Шулай да күңелләрендә нининдер җиңеллек хасил була. Һәм алар тагын укытырга булалар. Аннан соң – тагын. Шулай төрле сәбәпләр таба-таба яз кояшы назлый башлаганга кадәр атна саен Коръән укыталар. Моңа кадәр дингә-фәләнгә артык исе китмәгән ир, акрынлап, үзе дә намазга баса. Мәчеткә йөри башлый. Карчыгы аңа иярә.

Җәй җиткәч, ир ниндидер сәбәп белән өй түбәсенә менә дә ботын чабып көлеп җибәрә. Әллә ничә еллар элек салынган туфракны җил очыртып алып бетергән ләбаса, түшәм сайгаклары ялтырап күренеп ята. Хәтта такта арасындагы сылаулары да купшаклый башлаган. Мондый түшәмнән ничек салкын кермәсен ди?!

Түбәне ныгыта. Тик динен ташламый. Дөрес эшли, бер кереп, бер чыгып йөрергә дин ул маршрут автобусы түгел бит инде.

Әйтеп кенә бактым

Бу ни бу?

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне санап утырдым, бездә үзебезнең авыл кызларына өйләнүчеләр бик сирәк икән. Һәрберебезгә хатын әллә каян, читтән кирәк булган. Мин үзем дә шул исемлеккә керәм. Дөрес, бу кагыйдәдән искәрмәләр дә очрый, әмма бик сирәк.

«Күрше авылга килен сорарга киттеләр» кебек сүзләрне балачактан ишетеп үстек. Малай-шалай гына булсак та, килен төшәсе көнне кияү йорты тирәсендә бутала идек, күрше авыл кызларының ниндирәк икәнен күрәсе килде. Авылга кунак кыз кайтуы да галәмәт зур вакыйга саналды. Аны кичке танцылардан соң өенә озатып куяр өчен авыл егетләре сугышып-талашып бетәләр иде. Шул ук вакытта үзебездә чибәр, унган-булган кызлар үсеп җитеп, күрше авыл егетләре куенына керә тордылар.

Егетләрнең үзара шаяртып сөйләшүләрен дә хәтерлим әле. Алар бер-берсенә хатынны ераграк авылдан алырга киңәш итәләр иде. Беренчедән, кыз ераграк яшәгән саен серләрек тоелгандыр инде. Килен буласы кызның һәм кияү буласы егетнең нәсел-нәсәбе турында төрле имеш-мимешләр дә һәр ике якка барып җитә алмагандыр. Икенчедән, авыл ерак булгач, килен булып төшкән кыз әтиәнисе янына кире кайтып китә алмый. Чөнки юл газабы гүр газабына әйләнә, ул заманнарда аның машина-фәләне дә бик аз булган, җигүле ат төп транспорт саналган бит.

Ә бүген... Хәер, аерылышулар турында сөйләшмик әле. Мине күпме еллар узып та, кешенең һаман да «күрше тавыгы»на кызыгып яшәве уйландыра. Татарда буыннан-буынга яшәп килүче күркәм бер йоламы бу, әллә башка нәрсәме? Үземнең күпме дусларыма шалтыраттым: гомерлек юлдашны үз авылларыннан тапканнар юк дәрәҗәсендә. Бер дустым кызыклы гына мисал да китерде әле. Боларның авыллары бик зур икән, җиде йөзгә якын хуҗалык, ди. Күрше авылларга хатын эзләп барырга иренгән егетләр һич югы авылның икенче башында яшәгән кызларга өйләнәләр икән. Күрше булып яшәүче егет-кызларның гаилә коруын тарих белми, ди. Бәндә баласы ни өчендер гел билгесезлеккә омтыла, ерактагы һәр нәрсә, шул исәптән күрше авыл кызлары да серле булып тоела. Ә үз авылың кызы исә берничә тапкыр укылган китап кебек, аның инде берниндн кызыгы да юк. Хәтта аның нәселе дә йә яхшы, йә яман ягы белән бөтен авылга танылган була.

Халыкта «ерактагы кояш яктырак» дигән сүзләр бар. Бик уңышлы метафора дип кабул итеп, аны шагыйрьләр дә мулдан куллана. Ә гади авыл егете моны белми, ул турыда уйланмый да, һәм кирәге дә юк. Егеткә ачылмаган китап кебек серле зат кирәк. Ә серлелек кешене гомер буе үзенә тарта.

Бу юлларны ниндидер ачыш ясау максаты белән язмыйм. Читтән хатын алуны зур проблема итеп күтәрергә дә исәп юк. Тик менә яза торам, күңелгә әллә нинди кердел-чыктылы уйлар керә тора. Читтән хатын алгач, төрле авыллар белән йөрешергә, яңа дуслар, яңа туганнар табарга туры килә бит инде. Димәк, мәхәббәт җепләре татар яшәгән бөтен кыйтгаларны урап ала, безне үзара якынайта, туганлаштыра, бергә туплый дигән сүз. Без инде менә ничә еллар: «Бергә булыйк, бердәм булыйк!» – дип яшибез. Шактый гына олы җыеннар да шушы сүзләр белән тәмамлана. Димәк, татар гомер-гомергә тупланып яшәргә омтыла.

Сез нәрсә уйлыйсыздыр тагын.

БАЛАСЫЗЛЫК ӨЧЕН САЛЫМ,

ЯКИ ДЕМОГРАФИК КАТАСТРОФАДАН НИЧЕК КОТЫЛЫРГА?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Президентның соңгы Юлламасында төбәк җитәкчеләренә 12 төп бурыч куелды. Шуларның берсе – туу күрсәткечләрен яхшырту һәм гомер озынлыгын арттыру. Башка бурычлар янәшәсендә монысы аерым тора, чөнки, әйтик, газлаштыру, торак-коммуналь хуҗалыкны модернизацияләү, урта һәм кече бизнесны үстерү кебек максатлар аңлаешлы, чиновниклар боларга инвестицияләр табу, кредитлар юнәлтү кебек рычаглар ярдәмендә турыдантуры катнаша ала. Ә менә демография күрсәткечләрен ничек яхшыртырга?

Хәер, бездә монысы да акчага бәйле дип уйлыйлар: ана капиталын үстерсәң, социаль пособиеләрне арттырсаң, торак проблемасын хәл итсәң, балалар итәктән коелып кына торачак, дип фикер йөртәләр. Юк, автор каршы килми боларның берсенә дә, килешә: матди як гаилә корганда һәм балалар үстергәндә мөһим. Әмма статистика күрсәтә: демографик катастрофа икътисадый яктан алга киткән илләрдә күзәтелә. Үзбәкстанда, мәсәлән, демографик шартлау бара. Урта Азия республикаларында, гомумән, халык саны даими артуда, ә Үзбәкстан – лидер. Әле кичә генә укыдым: үзбәкләр бала өчен социаль пособиеләрне киметәләр, кайберләрен бөтенләй бетерәләр. Сәбәбе: балалар күбрәк туган саен, акча күбрәк кирәк, казнада кайдан акча җиткерәсең?

Ләкин уйларга кирәк: пособиеләрне киметү демографик шартлауны туктатмастыр, мөгаен. Пособиеләрне арттыру да бик әллә ни булышмый. Соңгы фикерне саннар белән дәлиллик. Башта туу коэффициенты дигән күрсәткечне алыйк һәм аның янәшәсенә җан башына туры килгән эчке тулай продуктны куйыйк. Үзбәкстанда туу коэффициенты бер хатынга – 2,90 бала, җан башына эчке тулай продукт (ЭТП) – 1983,06 доллар. Согуд Гарәбстанында туу коэффициенты – 2,46, җан башына ЭТП – 23185,87 доллар. Россиядә туу коэффициенты – 1,50, җан башына ЭТП – 12194 доллар. Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә туу коэффициенты – 1,46, җан башына ЭТП – 44315,55 доллар. Мәгълүматларның беренчесе – 2020 елгы, ЭТП 2021 елга карый. Нәтиҗәләр ясыйк: иң фәкыйрь ил – Үзбәкстанда туу коэффициенты иң югарысы, иң бай ил – Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә – иң түбәне. Бәлки, әмирлекләрдә бала табу матди яктан зыянлыдыр? Киресенчә, сабыйларның бу дөньяга килүен иң нык стимуллаштыручы илләрнең берсе шул инде. Яшьләр өйләнешер алдыннан Никах фондыннан һәрберсенә 20 мең доллар процентсыз кредит алалар. Бала туу белән кредит автомат рәвештә түләнгән дип санала. Бала туган өчен әти-әнигә 50 меңнән 200 мең долларга кадәр акча бирелә, кирәк булганда йорт та. Шуларга карамастан, илдә туу коэффициенты Россиядәгедән дә түбән.

Ил бай булган саен, балалар азрак туа, дигән нәтиҗә ясарга ашыкмагыз. Согуд Гарәбстанында да әниләрне һәм баларны социаль яклау системасы яхшы ук, халкы да фәкыйрьлектән интекми, ләкин туу коэффициенты янәшәдәге Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәгедән ике тапкырга якын диярлек югары. Димәк, үрчү проблемасы ул байлык-фәкыйрьлек проблемасы белән кисешми.

Мәсьәлә күпкә катлаулырак. Гаиләне матди яктан тәэмин итү буенча идеяләр соңгы вакытларда коелып кына тора. Россия бюджетында керемнәр өлеше гарәпләрнеке кебек үк кабармаган, шуңа күрә акчаны казнадан түгел, башка чыганаклардан эзләргә туры килә. Соңгы көннәрдә аеруча кызып иткән идея – баласызлык өчен салым түләтү. Гомеремнең СССРдагы өлешендә ул салымны берничә ел түләдем. 14 процент керем салымы, 6 процент баласызлык өчен ясак, профсоюз взносы һәм комсомол взносларын да кушкач, хезмәт хакымның 22 процентын тотып калалар иде. Салымнан качам дип кенә берәү дә өйләнергә дә, бала табарга да ашыкмый иде, әлбәттә. Табигый рәвештә хәл ителә иде барысы да. Хәзерге Россиядә андый салым кертү – СССРдагыдан мөшкелрәк эш. Рус нәрсә ди әле: «На каждого хитреца найдётся другой хитрец», – ди. Салым йөген арттырдыңмы, кешеләр күләгәгә күчәчәк. Болай да акчаны конвертта алучы күпме кеше барлыгын белеп бетермибез, сан артачак. Нәтиҗәдә бюджет оттырачак, балалы гаиләләргә ярдәм итәрлек акча да бик әллә ни күп җыелмас.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бала табып үстерүне стимуллаштыру өчен тагын бер кызык идея: балаларның хезмәт хакыннан тотып калына торган пенсия взносының яртысын әти-әниләргә пенсия итеп түләргә. Әйтик, улың эшли башлауга, сиңа инде күпмедер пенсия дә тия. Биш улың булып бишесе дә салым түли башласа, пенсия акчасы коела гына. Идеянең рациональ орлыгы бар төсле: картлыгың муллыкта үтсен дисәң, күп бала үстерәсең һәм аларны яхшы хезмәт хакы алып эшләрлек итеп тәрбиялисең. Бу фикернең дә бик күп йомшак яклары бар, ләкин без аларны тикшереп тормыйбыз. Без башта ук әйттек: бала туу матди якка бик әллә ни бәйле түгел. Фикерне саннар белән дәлилләдек тә.

Җәмгыять либеральрәк булган саен анда балалар азрак туа. Менә карагыз: Берләшкән Гарәп Әмирлекләре гарәп илләре арасында иң либерале, аны Көнбатыш дәүләтләреннән аерып алып та булмый кебек. Шуңа күрә әмирләр бала өчен күпме генә акча түләмәсен, анда туу коэффициенты Россиядәгедән дә түбән. Либеральлек соңгы вакытта хәтта Согуд Гарәбстанына да үтеп керә. Беренче тапкыр Согуд Гарәбстаныннан ярымшәрә хатын-кыз, мәсәлән, быел матурлык конкурсында катнашты. Нәтиҗәсен карагыз: 2000 елда илдә туу коэффициенты бер хатынга – 4,12. 2020 елда – 2,46. Либеральлекнең антонимы тоталитарлык дип аңламавыгызны үтенәм. Тоталитар җәмгыятьләр дә либераль була ала.

Либераль җәмгыятьләрдә хатыннар бала табарга теләми генә түгел, таба да алмыйлар. Бердән, тәртипсез җенси тормыш нәтиҗәсендә репродуктив функция юкка чыга: булачак әти-әниләр чирле. Икенчедән, ире дә, хатыны да сау-сәламәт булган гаиләләрдә дә, теләсәләр дә, бала тумый. Бу хакта мин моннан 17 ел элек «Либераль җәмгыять – төрмәме?» дигән язма биргән идем. Зоопаркта күпчелек хайваннар үрчеми бит әле, либераль җәмгыятьләрдә дә шундый эффект туа.

Зөһрә САДЫЙКОВА

АЛТЫН ЧЕБЕШЛӘР

КОШ-КОРТ АЛУ СЕЗОНЫ БАШЛАНДЫ

Чеби турында сөйләшергә иртәрәк әле, дип нәтиҗә ясарга ашыкмагыз. Йомырка салып, бәбкә чыгара торган казлары, үз инкубаторлары булганнарның эшләре инде гөрли. Җылы урыннары булганнар шулай ук бер тәүлеклек сары йомгакларны сатып алырга әзерләнә. Бәяләр тешләсә дә, авыл халкы арасында кош-кортка ихтыяҗ зур.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бәяләр артты

Питрәч районының Шихазда авылында яшәүче, озак еллар чебиләр үстереп сату белән шөгыльләнүче Зөлфия Шәйхесламова әйтүенчә, халык чебиләрне күпләп, гадәттә, май аенда алырга керешә. Бер тәүлеклек бройлерларны исә 8 мартта ук ала башлыйлар.

– Кош сайлап алу – үзе бер һөнәр. Мин, мәсәлән, яхшы партия эзләп, әллә кайларга барам. Авылга машина белән килеп сатучылардан алырга үзем дә шикләнер идем. Чөнки чебиләрне ничек алып кайтканнар, күпме вакыт сусыз барганнар, чиста шартларда тотканнармы – белеп булмый. Шул арада да чебиләр чир ияртеп, яңа хуҗасы кулында кырыла башларга мөмкиннәр. Бер көнне тавык, икенче көнне шул ук читлеккә тәүлеклек чеби куярга да куркыныч. Нәтиҗәдә кошларның 30 проценты үләргә мөмкин. Ел саен төрле кешедән алганчы, бер намуслы сатучыны табу яхшырак, минемчә, – ди ул.

Хәзер чеби-бәбкәне инкубаторда чыгаручылар да күп. Җылы урыннары булганнар кош-кортларны теләсә кайсы ел фасылында асрый. Саба районында яшәүче Сәлахиевлар гаиләсенең инде менә ун ел тирәсе ел дәвамында яңа эшкәртелгән кош итеннән өзелгәннәре юк.

– Без тавык итен бик яратып кулланабыз, шуңа күрә ел дәвамында инкубатордан чеби чыгарып үстерәбез, – ди Фәнис Сәлахиев. – Соңгы вакытларда йомырканы Төркиядән кайтартабыз да үзебезнең инкубаторда чыгарабыз. Әлеге вакытта унсигез, кырык көнлек чебиләребез бар. Сатар өчен түгел, бары тик үзебез өчен генә тотабыз аларны.

Гаилә башлыгы йомырка бәяләренең кинәт артуын да әйтте. Әйтик, кышын бер йомырка 49 сум торган булса, хәзер аны 69 сумнан да арзанракка табып булмый икән.

– Чеби сезоны башланды, дип әйтергә була инде. Аларны 320–380 сумга саталар. Һәркем чебине үз тәҗрибәсеннән чыгып үстерә. Без аларга йомыркадан чыгуга, өч көн дәвамында баллы су эчертәбез. 16 көнгә кадәр – бер төрле, аннан соң 34 көнгә кадәр башка төрле катнаш азык бирәбез. Шуннан соң бодай ярмасын кушабыз. Чебигә коры ризык кына ашатырга кирәк. Эремчек ашату да файдалы, ул протеинны күтәреп җибәрә. Чеби үстергәндә иң төп факторлар – яхшы нәсел, җылы, коры чиста урын.

Алабуга районында яшәүче Гөлсем Абдуллинаның бик тә нык мәшәкатьле чоры: ике йөзләп казы йомырка сала башлаган.

– Узган ел гыйнварда утырганнар иде, быел суыклар нәтиҗәсе булдымы, соңладылар. Февраль урталарында гына йомырка сала башладылар. Шуларны җыеп алып, унбиш көн эчендә инкубаторга куябыз. Анысының да температурасын, дымлылыгын гел карап, күзәтеп торырга кирәк.

> Каз бәбкәсе – 30, тавык – 21, үрдәк 36 көннән соң чыга. Аларның һәркайсын бала тәрбияләгәндәй карарга кирәк, тик барыннан да бигрәк күркә бәбкәсе нәзберек. Чыкканнан соң аны бик сакларга кирәк. Җил дә, суык та ярамый. Ә аслары барысыныкының да гел коры булырга тиеш. Кошлар чисталык ярата.

Аслары юеш, пычрак булса, алар ятмый да. Кычкырып тик йөриләр. Шуңа күрә йомычка чүбен әледәнәле алыштырып торабыз, кызыл лампалар кабызабыз. Алларыннан чиста суны өзмибез, – ди ул.

Чыгарган чебиләрен халыкка саталар. Дөрес, кешеләр беренче партиядән чыккан кош-кортны алырга ашыкмый әле, бәбкәләр артыннан гадәттә май башларында гына киләләр, ди.

– Әлегә бездән бәбкәләрне теплица тотучылар гына алып китә. Самара өлкәсеннән кадәр килеп алалар. Калганнарын үстереп сатабыз. Кемдер – ике атналыкны, кемдер бер айлыкны сорый. Тик соңгы елларда бер айлык казларга ихтыяҗ күпкә зуррак. Үсеп җиткәннәрне генә алучылар да күп. Чөнки хәзер кешеләр мал тотмый, җылы урыннары юк, – ди Гөлсем ханым.

Ул әлегә чеби бәяләренең билгеле булмавын, тик артуын әйтте. Бу логистикага да, йомыркаларның сыйфатына да бәйле, ди.

– Күп кенә фермерлар читтән кайтарылган йомыркаларның чыгышы начар булуга зарлана. Үзебезнең казлар салганы гына җитмәгәч, йомыркаларны сатып та алабыз. Узган ел кайтарткан йомыркаларның яртысы ватык иде, бер токым дип алып, бөтенләй башка булып чыкты, – диде ул.

Исемен күрсәтергә теләмәгән алыпсатар ханым да быел кош-корт бәяләренең бик артуын әйтте.

– Ләкин барыбер халык күпләп ала, чөнки күпләр олы терлек асрамый, ә кош-кортның мәшәкате азрак, – диде ул. – Язын, көзен кызыл һәм ак тавыклар сатабыз. Сату сезоны инде башланды. Бүген мин дүрт айлык кызыл тавыкны 420 сумга сатам.

Кара итле тавыклар

Без балачактан ук күреп ияләшкән, урам тутырып сибелешкән сары йомгаклардан тыш, соңгы елларда төрле төсле чебешләр, экзотик кош-корт үрчетүчеләр дә артты. Әйтик, Казанның бер бистәсендә яшәүче Лилия Дмитриева хуҗалыгында нинди генә кош-корт юк: тавык, бытбылдык, көртлек, күркә, фазан, үрдәк, каз, тәвә кошы. Хәтта экзотик токымлы эмо дигән кош та бар.

– Барлык чебешләрне үзебезнең инкубаторда чыгарабыз. Әлеге көндә йомырка сала торган тавык, бытбылдык йомыркаларын куйдым. Казан янындагы бистәләрдә яшәүчеләр дә йомырка сала торган тавыклар, бройлерлар тоталар, чөнки күпләр хәзер сәламәт туклану, сәламәт азык-төлек белән кызыксына. Үзең җитештергән һәрвакыт ышанычлы бит. Ә кош-кортларның артык мәшәкате юк, уңайлы урын гына булсын, – ди.

Экзотик токымнар белән мавыкса да, Лилия хуҗалыкта ит, йомырка өчен элеккеге, бар кеше дә белгән, безнең табигать шартларына җайлашкан токымнарны («Кучинская юбилейная», «Адлерская серебристая», «Пушкинская», «Голошейная») алырга киңәш итә.

– Хәзер төрле төстәге йомыркалар бик популяр, – ди ул. – Алар шоколад, яшел, алсу, зәңгәрсу төсләрдә була. Моннан тыш, кара итле тавыклар да бар. Аларның барлык эчке әгъзалары, тире, сөяк, итләре кап-кара. Андый тавыклар миндә дә бар иде.

Лилия киләчәктә агротуризм юнәлешендә моңа кадәр Россиядә булмаган «Инкубация йомыркасы музее» эшләтеп җибәрергә планлаштыра. Ул әлеге проектын «Фермерлар мәктәбен»дә тәкъдим иткән.

– «Фермерлар мәктәбе»нең дәрәҗәсе елдан-ел арта. Узган ел 100 мең сум акча бирделәр. Анда укып чыккач, кошчылыкка карашым үзгәрде, күп нәрсәләргә башкача карый башладым. Документлар белән эшләргә дә өйрәттеләр. Хыялымдагы музей төрле яшьтәге кешеләрне бер урынга җыярга ярдәм итәр иде. Монда без беренче инкубаторлар барлыкка килү тарихын, йомырка һәм кош-корт төзелешен өйрәнәчәкбез, балалар өчен экскурсия, фотосессияләр оештырачакбыз. Зурларга исә колбаса, сыр ясау буенча мастер-класслар уздырырга ниятлибез. Проектыбыз белән Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында да кызыксындылар, – ди Лилия Дмитриева.

Белгеч фикере

Ралинә БӘШИРОВА, фермер

– Бер тәүлеклек чеби алу отышлымы, әллә бераз үскәннеме?

– Күпләп алганда, бер тәүлеклек чеби алу отышлырак. Эре хуҗалыкларның күпчелеге шулай үстерә, чөнки алар 30 көннән соң ул чебине сата. Бик сирәкләре генә ике ай үстереп, иткә әзерли. Ә казларның бер айлыкларын алырга киңәш итәм, чөнки алар – авыруларга тизрәк бирешә торган кош.

– Бройлерны ничек тәрбияләргә кирәк? Ул нәрсә ярата?

– Бройлерга махсус алар өчен җитештерелгән катнаш ризык бирергә кирәк. Аның составында чебигә үсәр өчен нәрсә кирәк, барысы да бар: витаминнар, борчак, көнбагыш мае, акбур һәм башкалар. Чебинең яшенә карап, аларның составлары аерыла. Төрле үсеш этабында «старт», «предстарт», «рост», «финиш» дигәнне карап алырга кирәк. Чебиләр бер айга кадәр катнаш ризык ашый, күп су эчә. Аннан соң рационнарына мөмкин кадәр күбрәк яшел үлән, кычыткан бирсәң яхшы. Теләсә нинди кош-кортны үстергәндә истә тотарга кирәкле алтын кагыйдә: ул – чисталык. Чебиләрнең асты һәрвакыт коры, чиста булырга тиеш. Һәм, әлбәттә, алларыннан суны өзмәү кирәк. Моннан тыш, бройлер чебиләрне ишегалдына кызыл тавык кебек чыгарып җибәрергә ярамый. Андый бройлерлар ябык була. Алар өчен махсус челтәр белән уратылган, артык чабып йөрмәслек урын яхшы. Чебиләрнең тере килеш авырлыгы 3,8–4,5 килограммга кадәр булса яхшы. 5 килограммнан арткан кошларның ите каты була. Тәме дә яшь чебинеке кебек тәмле булмый.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

ЯЗГЫ (СА)ТАШУ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Илдар Мөхәммәтҗанов

Халык әйтсә...

Акты ташып, акты ярсып кар сулары... Тик болай җырларга иртәрәк, ди Арча районының Ашытбаш авылында яшәүче халык синоптигы Рәис Шәкуров. Аның әйтүенчә, чын яз 21 марттан соң гына киләчәк әле.

– Хәзерге вакытта хут суыклары хакимлек итә. Ул мартның 19ына кадәр дәвам итәчәк. Шуннан соң кыш үз дилбегәсен җибәрә. Мондый суыклар бик әйбәт. Чөнки җәй җылы булачак. Кояшы да кыздырыр, яңгыры да вакытында явар, җиле дә исәр. Авылда әлегә яз исе килә дип әйтеп булмый. 21 мартта – көн белән төн тигезләшкәч, борын сизә башлый аны, – ди Рәис Шәкуров.

Җылы яктан очып кайткан кара каргалар да кабат югалган әнә.

– Кара каргаларны 4 мартта күрдем, – ди Балтач районының Яңгул авылында яшәүче халык синоптигы Әмир Шәрәфиев. – Алар берән-сәрән генә очты да, һава торышы төнлә 25 градус салкынга кадәр төшкәч, юкка чыктылар. Кара каргалар суыктан курыкмый. Аларга ашарга кирәк. Кошлар кар эри башлагач, калдыклар белән туклана. Ә быел кар бик күп. Кара каргалар килеп күзәтеп киттеләр дә тагын юк булдылар.

Быелгы язның үзенчәлеген дә әйтте халык синоптигы.

– Яз озын булачак. Үзегез күреп торасыз, ул иртә башланды, әмма сузылды. Шуңа күрә озак киләчәк. Кыш көне кар күп яугач, халык язгы ташудан курка инде. Ул апрельнең икенче яртысында гына булыр әле. Мин үзем авыл янәшәсендәге Шушма елгасы үзәнен күзәтәм. Районлагы Борнак дигән авылда бер елны да су басмыйча калганы юк. Аргы як дигән өлешендә хайваннарны да күтәртеп куялар, бәрәңгеләрен дә чормага менгезәләр. Быел исә ах-вах итәрлек сәбәп юк. Язгы ташу көчле булмаячак. Ник дисәң, җирдә туң начар, – ди Әмир Шәрәфиев.

«Уҗымнар юештә ята»

Туң дигәннән, авыл хуҗалыгы тармагы белгечләре быел бер яктан кар күплегенә сөенсә, икенче яктан туфракта туң катламы аз булуына борчыла.

– Карның күп булуы әйбәт, әлбәттә. Элек бабайлар аны ашлама дип әйтәләр иде. Тик карның ничек эрүеннән дә күп нәрсә тора бит әле, – ди Кукмара районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү бүлеге җитәкчесе Илдар Габбасов. – Әгәр көннәр кисәк җылытып җибәрә икән, бу безгә файдага түгел. Чөнки кар суларын мөмкин кадәр җиргә сеңдереп калырга кирәк. Яз акрын гына килеп, апрельнең уннарына кадәр җебетсә, бик яхшы.

Балтач районының «Якты юл» хуҗалыгында уҗымнарны шушы көннәрдә генә тикшереп караганнар.

– Быелгы кебек карлы кыштан соң туфракта туң булмау бер яктан шатландырса, икенче яктан көендерә, – ди егерме елдан артык районлагы Тимирязев исемендәге хуҗалыкта баш агроном булып эшләгән, хәзер «Якты юл» хуҗалыгына җитәкче итеп билгеләнгән Азат Ганиев. – Ник дисәгез, уҗымнар бераз авыррак хәлдә. Хуҗалыкта көзге культураларның торышын әле яңа тикшердек: туфракта 5 сантиметр тирәнлектә 2,2 градус җылы. Уҗымнар юештә ята, суларга һавалары аз. Бу – алар өчен уңайлы шарт түгел. Ә кар катламы калын. Шуңа күрә көзге бодай начар чыгарга да мөмкин. Икенче яктан караганда, яз тиз килмәсә, эрегән сулар сеңеп барачак. Көздән дә һава торышы бик яңгырлы булмады, туфракка дым начар кереп калды. Кар белән кирәкле дым күләме җыелыр дип өметләнәбез.

Гомумән дә, авыл кешесенең мәшәкате җитәрлек бу арада. «Авылда язгы ташуга әзерлек узган атнада ук башланды. Су ташу куркынычы янамаса да, бәласеннән башаяк дигәндәй, бөтен күпер тирәләрен экскаваторлар белән чистартып куйдылар», – ди Азат Ганиев.

Сан

Быелгы кышның кайсы аенда юл һәлакәтләре саны күбрәк теркәлүе билгеле. «Росгосстрах» мәгълүматларына караганда, гыйнварда юлдагы авария турында мөрәҗәгать итүчеләр саны – **35%**, гыйнварда – **34%**, ә февральдә **31%** тәшкил иткән. Юл һәлакәтләре иң күп теркәлгән төбәкләр – Мәскәү, Мәскәү өлкәсе, **Татарстан** һәм Башкортстан.

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ЯЗ

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Министрлар Кабинетында язгы ташуга әзерлеккә багышланган киңәшмәдә быелгы язны, кыш көне кар күп яву аркасында, үзенчәлекле булачак, дип атады. Муниципаль берәмлекләргә һәм Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына язгы су ташуга бәйле тиешле чаралар күрергә, аерым алганда, су басу куркынычы янаучыларга вакытлыча тору урыннары әзерләргә кушты ул. «Иң мөһиме – халыкның куркынычсызлыгын һәм сәламәтлеген тәэмин итү», – диде Татарстан Рәисе.

Ташуны көтәләр

Язгы ташуга, кем әйтмешли, кыштан ук әзерләнүче авыллар да бар.

Татарстан Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының матбугат хезмәте мәгълүматларына караганда, былтыр республиканың 39 районындагы 200дән артык торак пунктка су басу куркынычы янаган.

Буа районының Бәбки авылында яшәүчеләр, мәсәлән, бу хәлгә тәмам ияләшеп беткән. Язгы ташу чорында алар зур юлдан, гомумән дә, өзелә.

– Авыл халкына фельдшер алдан ук җитәрлек күләмдә тиешле даруларны таратып чыкты. Азык-төлек белән дә тәэмин иттек, – ди Бәбки авылы караган Килдураз авыл җирлеге башлыгы Зөлфәт Әхатов. – Ул авыл зур түгел. Барлыгы унлап кеше яши. Нигездә – пенсия яшендәгеләр. Күпбалалы бер гаилә ташу алдыннан бу якка чыгып кала. Бәбкидә яшәүчеләр язгы ташуны табигый хәл итеп кенә кабул итә, артык исләре дә китми. Ташу чорында алар белән даими элемтәдә торабыз. Бер-бер хәл булса, коткаручылар бар. Авылга – резин көймәдә, соңгы чиктә ерактан урман аша әйләнеп кереп була.

Авыл халкы белән дә сөйләштек.

– Безнең бар да яхшы. Язгы су ел саен килә дә китә ул, – ди артык исе китмичә генә авылда яшәүче Алик Кәримов. – Җирле хакимият барысын да алдан кайгыртa, бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итәләр. Бәбкидә 1994 елдан бирле яшибез, ел саен бер үк хәл. 1970 нче елларда су хуҗалыкларга кадәр кергән дип сөйлиләр. Хәзер алай ук куркыныч түгел, иң беренче чиратта, авылдан чыга торган юл өзелә. Он, ярма ише кирәк-яракны алдан ук сатып алып куйдык, калганы үзебездә бар. Ике кәҗә тотабыз. Мин сиксән яшьтән уздым, тормыш иптәшем сиксәнгә җитә. Әнә шулай яшибез.

Яшел Үзән районында исә язгы ташу чорында чын мәгънәсендә суда йөзгән Татар Танае авылында быел язны курыкмыйча көтәләр.

– Безнең якта Гөбенә елгасы ярларыннан ташый. Узган елның җәендә авыл янәшәсендә судан саклау дамбасы төзелде. Шуңа күрә быел язны җиңелрәк чыгарбыз, бар да әйбәт булыр, дип өметләнәбез, – ди Мамадыш-Әкил авыл җирлеге башлыгы Фәнис Мирхәтуллин.

Авыл халкы, мондый көннәрне дә күрәсебез бар икән, дип куана әнә. Хәтерләсәгез, былтыр Татар Танаенда яшәүче Рәшит Габдерәхимовларның абзардан алып өйгә кадәр тоташтан су астында калган хуҗалыклары төшерелгән видеоязмалар бөтен социаль

Түбәдәге кар, боз сөңгеләре өчен кем җаваплы?

Быелгы кебек карлы кышны йорт түбәләре дә «күтәреп тора» алмады. Татарстанның төрле районнарыннан моңа бәйле хәвеф-хәтәр очраклары турында хәбәрләр килә. Яшел Үзәндә 8 яшьлек бала түбәдән төшкән кар астында калды. Лениногорскида студент кыз шундый ук бәлагә юлыгып, зыян алды. Казанның ТЭЦ урамындагы металл җыю бинасы түбәсе кар авырлыгыннан ишелеп, бер кеше һәлак булды. Дәрвишләр бистәсендә исә кибет алдындагы түбә җимерелү аркасында чак кына фаҗига чыкмады. Йорт түбәләрен кардан, боз сөңгеләреннән чистарту өчен кем җаваплы?

Артур РУСАКОВ, торак мәсьәләләре буенча юрист:
– Күпкатлы йорт түбәсен чистарту өчен – идарәче оешма яки торак милекчеләре ширкәте, ә торак булмаган биналарны тиешле тәртиптә тоту өчен милек хуҗасы җаваплы. Ә менә боз сөңгесе тәрәзә төбеннән яки фатирдан чыгарылган кондиционердан төшеп, кемгә дә булса зыян китерә икән, моның өчен милек хуҗасына җавап бирергә туры киләчәк. Вазыйфаи затларга 15–30 мең сум күләмендә штраф яный, кабат тотылсалар, штраф 50 мең сумга кадәр җитәргә мөмкин. Юридик затларга исә ул 1 миллион сумга кадәр тәшкил итә. Кардан чистартылмаган яки боз сөңгеләре «үскән» түбәләр турында «Открытая Казань» яки «Халык контроле» порталлары аша хәбәр итәргә мөмкин.

челтәрләрдә таралды. Быел күңел тыныч, ди Рәшит абый.

– Соңгы берничә елда язгы ташу аеруча да көчле булып, өйгә кадәр керде. Шуңа күрә алдагы елларда диван-суыткычларга кадәр барысын да югарырак күтәреп куя идек. Быел ташуга алай алдан әзерләнмәдек. Умарталарга да тимәдем әле. Быел берсен дә күчермәскә исәп. Су басуның ни икәнен үз башыннан үткәннәр генә белә ул. Минем әтием 1904 елгы. Ул, бакчада гомер буе бәрәңге дә утыртмый идек, дип сөйли иде. Мин 1969 елдан су баса башлаганны хәтерлим. Ул елны хуҗалыктагы сарыкларны колхоз көймәсе белән кереп коткардык. Соңгы елларда бигрәк тә үзәккә үтте язгы ташу. Шуңа күрә уйладым-уйладым да көннәрнең берендә бу хакта район башлыгына мөрәҗәгать итәргә булдым. Йөри торгач, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка кадәр хат яздым. Гомумән алганда, биш ел вакыт узды. Җирлек башлыгына да, район җитәкчелегенә дә бик зур рәхмәт. Аллага шөкер, былтыр дамба төзелешенә 75 миллион сум акча бүлеп бирелде. Ныклы корылма төзеделәр, – ди Рәшит Габдерәхимов.

Тәңкәнең икенче ягы

Карлы кыш юлчыларның да төн йокысын качырды.

– Татарстанның 27 районында автомобильләр хәрәкәт итүче 132 юл участогына су басу куркынычы яный, – ди «Главтатдортранс» оешмасы җитәкчесе Эдуард Данилов. – Бәла-каза килеп чыккан очракта, әлеге юлларны әйләнеп узу маршрутын тәэмин итү өчен, биредә кизүләр оештырылачак.

Әйтүләренә караганда, төбәк дәрәҗәсендәге юлларда барлыгы 1093 күпер бар. Шуның 459ы – кечкенә корылмалар. Татарстандагы барлык күперләрнең 65 проценты язгы ташуга әзер икән. «Бүген республика күләмендә күперләр, сууткәргеч торбалар, улакларны чистарту эше дәвам итә. Күперләр тирәсендә боз калынлыгы уртача 60–90 сантиметр тәшкил итә», – диде Эдуард Данилов.

Кар – муллык билгесе, дисәләр дә, быелгы кыш кесәгә дә суккан.

– Бураннар вакытында Бөреледәге бакчама барырга җай чыкмады. Соңрак килсәм, кар теплица тышланган поликарбонатны сындырган. Урта бер җирдә тимерләренә дә зыян килгән. Шуңа күрә төзәтеп кенә куя торган да түгел. Яңасы 16–18 мең сум тора. Нишләтәсең, сатып алырга туры киләчәк, – ди Биектауда яшәүче һәвәскәр бакчачы Нәҗия Хәйруллина.

Язга бәйле киңәшләрен дә бирде ул. «Бакчадагы яшь агачларны һәм куакларны кайгыртырга кирәк. Чөнки мондый һава торышында кар өстендә каты «кабык» барлыкка килә. Ә ул яшь ботакларны сындырырга мөмкин. Аларны чистарту зарур. Тик менә агач төпләренә тимәвең хәерлерәк. Дым күп булгач, кояшта агачның кәүсәсе бүртә башлый, ә төнге суыкта катып ярыла. Быел кар күп булгач, язның озаграк килүе әйбәтрәк. Югыйсә язгы сулар күздән утыртып калдырган сарымсак-суганнарны черетергә мөмкин. Гомумән, быел бакча эшләрен бераз кичектереп торырга киңәш итәләр. Туфрак соң өлгерә», – ди бакчачы.

Кайчан җылыта?

Моннан ары каты суыклар булмаячак, ә җир өсте кардан 12 апрельдән соң арчылачак, ди синоптиклар.

– Мартның беренче ун көне гадәттәгедән җылырак булды. Һава температурасы хәзер дә климатик нормадан югарырак. Татарстанда көндез 2–4 градуска кадәр җылыта. Төнлә исә термометр баганасы 0 градустан түбән төшеп китә. Шуңа күрә әлегә язгы ташудан куркасы юк, – ди КФУның Метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев. Аның әйтүенчә, чын яз 1 апрель тирәсендә башланачак. Чөнки нәкъ менә шул вакытта һава торышы 0 градуслык чикне узачак икән.

– Быел кыш көне кар күп булды. Хәзер кар катламының биеклеге уртача 68 сантиметр тәшкил итә. Тик бу гайре-табигый хәл түгел. Күпьеллык күзәтүләргә караганда, соңгы дүрт елда бу вакытта кар катламының биеклеге 60 см чамасы тәшкил иткән. Чагыштыру өчен: 2011 елда март башында әлеге күрсәткеч 90 сантиметрга җиткән. Алай гына да түгел, март азагына кадәр өстәлеп, 27 март көнне 1 метр чикне узган ул. Быел исә язның беренче ае явым-төшемнәргә саран. Айлык норма 38 мм булса, март башыннан бирле нибары 6 мм кар яуды. Алга таба артык явым-төшемнәр көтелми. Кар акрынлап эри башлады инде. Җир өсте 12 апрельдән соң кар катламыннан арчылачак, – диде Тимур Әүхәдиев.

ТАМАК ХАКЫ

21,1 мең сум. Илкүләм финанс тикшеренүләре агентлыгы (НАФИ) мәгълүматларына ышансаң, Россиядә яшәүчеләрнең азык-төлеккә дигән айлык чыгымнары соңгы ике ел эчендә 4,5 меңнән 21,1 мең сумга кадәр арткан. Тамак хакы, чыннан да, шулай зурмы? Алдан ук кисәтик: язмада саннар күп булачак.

Росстат тикшеренүләренә караганда, бер ел эчендә кулланучылар кәрзиненә кергән 47 продуктның сигезенең генә бәясе төшкән, калганнары исә бәя ягыннан өскә үрмәләгән. Алар моны 2023–2024 елларның 27 февраль – 6 март арасындагы бәяләрне чагыштырып ачыклаган.

Росстат мәгълүматларын исәпкә алып, «ВТ» хәбәрчесе дә Казанның берничә кибетенә азык-төлек кәрзине тутырырга чыкты.

Кәрзин туплаганда товарларның иң арзаны да, иң кыйммәте дә түгел – шулар арасында уртача бәядән булганы алынды. Бер айга исәпләнгән минималь кулланучы кәрзиненә түбәндәге азык-төлекне керттек: ипи, ярмалар, бәрәңге, яшелчәләр, макарон, җиләк-җимеш, шикәр, ит (тавык ите, сыер ите), ит ризыклары, балык, сөт һәм сөт ризыклары, йомырка, май, үсемлек мае, чәй, тоз. Товар сатып алганда махсус ташламалар бирә торган купон, карталар исәпкә алынмады.

Бер айга күпме ипи, ничә литр май кирәк дип баш ватасы түгел. Хөкүмәт бер елга кемгә күпме тиешен алдан ук билгеләп куйган күрсәткечләрне айлар санына бүләсе. Ул күрсәткечләр түбәндәгечә.

Бәрәңге	100,4 кг
Яшелчә	114,6 кг
Җиләк-җимеш	60,0 кг
Шикәр һәм тәм-томнар	23,8 кг
Ит ризыклары	58,6 кг
Балык ризыклары	18,5 кг
Сөт һәм сөт ризыклары	290,0 кг
Йомырка	210 данә
Үсемлек мае, маргарин һ.б.	11,0 кг
Тоз, чәй һ.б.	4,9 кг
Ипи һәм икмәк ризыклары (макарон, он)	126,5 кг

Без исә дүрт төрле кибеттәге товарларны чагыштырып карадык. Бер айлык товар сатып алмадык, билгеле. Бер кешегә җан асрау өчен якынча бер атнага җитәрлек иң кирәкле саналган продукциянең кайда күпмегә тәкъдим итүләрен ачыклау иде максатыбыз. Араларында киң даирә сатып алучылар өчен дә, продукциясе кыйммәтле саналган кибет тә бар. Кайсына керәсен укучы үзе хәл итә.

Товар	«Пятерочка»	«ВкусВилл»	«Верный»	«Магнит»
Ипи	47 сум	135 сум	25 сум	58 сум
Шикәр	60 сум/кг	85 сум/кг	65 сум/кг	60 сум/кг
Бәрәңге	150 сум (3 кг)	179 сум/5 кг	150 сум (3 кг)	150 сум (3 кг)
Яшелчә (кыяр/помидор/кәбестә/суган)	150 сум (600 г)/ 176 сум (800 г)/ 105 сум (3 кг)/ 21 сум (500 г)	200 сум (600 г)/ 297 сум/(600 г)/ 153 сум (2,5 кг)/ 38 сум (710 г)	170 сум/кг/ 200 сум (600 г)/ 126 сум (3,5 кг)/ 33 сум/кг	160 сум (600 г)/ 240 сум (700 г)/ 65 сум/кг/ 39 сум/кг
Балык (минтай)	200 сум (400 г)	500 сум (630 г)	240 сум (400 г)	240 сум (600 г)
Ит (тавык/күркә)	439 сум (2 кг)/ 269 сум (410 г)	507 сум (1,42 кг)/ 284 сум (400 г)	450 сум (2,5 кг)/ 290 сум (410 г)	384 сум (2,4 кг)/ 269 сум (410 г)
Йомырка	137 сум (600 г)	152 сум (650 г)	150 сум (749 г)	130 сум (600 г)
Үсемлек мае	110 сум/л	155 сум/л	120 сум/л	100 сум/л
Сөт	64 сум (930 мл)	78 сум (900 мл)	72 сум (930 г)	70 сум (930 мл)
Сөт ризыклары (каймак/сыр/кефир)	46 сум (220 г)/ 170 сум (200 г)/ 35 сум (430 мл)	99 сум (200 г)/ 247 сум (200 г)/ 94 сум/л	56 сум (250 г) /200 сум (200 г)/ 33 сум (430 г)	46 сум (220 г)/ 230 сум (200 г)/ 35 сум (430 мл)
Чәй (пакетлы)	100 сум (50 г)	155 сум (50 г)	106 сум (50 г)	95 сум (50 г)
Тоз	74 сум (550 г)	77 сум (500 г)	68 сум (500 г)	72 сум (550 г)
Ярма (дөге/карабодай)	120 сум (800 г)/ 124 сум (800 г)	155 сум (800 г)/ 155 сум (800 г)	100 сум (800 г)/ 140 сум (800 г)	120 сум (800 г)/ 124 сум (800 г)
Җиләк-җимеш (алма/банан)	144 сум (1,2 кг)/ 168 сум (1,2 кг)	165 сум (940 г)/ 174 сум (1,1 кг)	120 сум/кг/ 170 сум/кг	100 сум/кг/ 140 сум/кг
Нәтиҗә	**2909 сум**	**4084 сум**	**3084 сум**	**2927 сум**

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

18 март | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
08.00 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30 «Халкым минем...» 12+
12.00, 23.10 «ИСЕМЕМ ЦЗЮНЬ ЦЗЮ ЛИН» 16+
13.00 «Ком сәгате» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Халкым минем...» 12+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
19.00, 22.10 «Фирдус Тямаев концерты» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «НИТИ ЛЮБВИ» 12+
00.45 «Каравай» 6+
01.10 «Соотечественники» 16+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Кызган казан» 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «Под небом Крыма» 12+
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.45, 19.30 Информационный канал 16+
17.30 Вечерние новости
18.00 Митинг-концерт «10 лет в родной гавани»
21.00 «Время»
22.00 «ПЕРЕВЕДИ ЕЁ ЧЕРЕЗ МАЙДАН» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Александр Проханов. Исповедь» 18+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ВАСНЕЦОВА» 12+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.40 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.10, 13.55 Новости
07.05, 18.55, 21.55, 00.20 Все на Матч!
10.05 «История Джесси Лингарда» 16+
11.10, 00.55 Еврофутбол. Обзор 6+
12.15 Смешанные единоборства. One FC. Анатолий Малыхин против Ренье де Риддера 16+
13.35 Специальный репортаж 12+
14.00 «Есть тема!»
15.20 «Громко»
16.15, 19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/4 финала
22.35 Смешанные единоборства. UFC. Тай Туиваса против Марчина Тыбуры 16+
01.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Факел» – «Кузбасс» 6+
04.00 Прыжки в воду. Кубок Евразийских стран 0+

НТВ

04.55 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. МОРЕ И ГОРЫ» 12+
22.10 «ПРЕТОРИАНЕЦ» 16+
00.50 «ПОД ПРИКРЫТИЕМ» 16+
03.25 «ДОЗНАВАТЕЛЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.25, 04.10 «Давай разведёмся!» 16+
08.25, 02.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.00 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.05 «Порча» 16+
12.55, 01.05 «Знахарка» 16+
13.30, 01.35 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «НЕРОДНАЯ ДОЧЬ» 16+
05.00 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «ВИКИНГ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «ДОБРОВОЛЬЦЫ» 12+
13.25, 20.05 «По горячим следам» 16+
13.45, 03.25 «АНДРЕЕВСКИЙ ФЛАГ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50, 19.55 «Специальный репортаж» 16+
20.25 «Сыновья уходят в бой» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ГАИШНИКИ» 16+

19 март | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15, 00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ИСЕМЕМ ЦЗЮНЬ ЦЗЮ ЛИН» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Әдәби хәзинә» 6+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Заман көзгесе» 6+
18.00 «Национальный калейдоскоп» 12+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «НИТИ ЛЮБВИ» 12+
00.00 «Видеоспорт» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «Под небом Крыма» 12+
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.45, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ПЕРЕВЕДИ ЕЁ ЧЕРЕЗ МАЙДАН» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ВАСНЕЦОВА» 12+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
03.40 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 09.30, 13.55, 15.50 Новости
07.05, 15.55, 21.55, 00.20 Все на Матч!
09.35, 04.00 Лыжные гонки. Альфа-Банк Чемпионат России
13.35 Специальный репортаж 12+
14.00 «Есть тема!»
15.20 «География спорта. Тула» 12+
16.45, 19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/4 финала
22.35 Дартс. OLIMPBET Международная лига. Тур 2
00.55 Матч! Парад. Лучшие голы 6+
01.25 «Магия большого спорта» 12+
01.55 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. ЦСКА – «Кубань» 6+
03.25 «Что за спорт?» 12+

НТВ

04.55 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. МОРЕ И ГОРЫ» 12+
22.10 «ПРЕТОРИАНЕЦ» 16+
00.45 «ПОД ПРИКРЫТИЕМ» 16+
02.35 «ДОЗНАВАТЕЛЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.30, 04.20 «Давай разведёмся!» 16+
08.30, 02.40 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.05 «Понять. Простить» 16+
11.55, 00.15 «Порча» 16+
13.00, 01.15 «Знахарка» 16+
13.35, 01.50 «Верну любимого» 16+
14.10, 02.15 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «Кризисный центр» 16+
19.00 «НЕРОДНАЯ ДОЧЬ» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «КОМАНДИР СЧАСТЛИВОЙ «ЩУКИ» 12
13.25, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.45, 03.20 «АНДРЕЕВСКИЙ ФЛАГ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ГАИШНИКИ» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 18 март

06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Актуаль әңгәмә»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 20.40 Трансляция радио России
11.10 «Шигърият». Гарифҗан Мөхәммәтшин һәм Илдус Гыйлаҗев әсәрләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Вахит Имамов. «Гөлҗиһан». Моноспектакль
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 19 март

06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Актуальное интервью»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.10 Прямой эфир
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 20.40 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Клара Булатова шигырьләренә җырлар

Чәршәмбе, 20 март

06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Юллар чатында»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.20 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 20.40 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Лирик музыка концерты

Пәнҗешәмбе, 21 март

06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Перекресток»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Прямой эфир
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 20.40 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «На волне Татарстана»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар»

Җомга, 22 март

06.00 «Иртәнге нур»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 20.40 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Эстрада музыкасы концерты

Шимбә, 23 март

8.10 Дилә Булгакова әсәрләреннән әдәби-музыкаль композиция
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Табигать дуслары»
10.30 «7 көн»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Ренат Харис. Поэмалар

Якшәмбе, 24 март

08.10 «Между Волгой и Уралом»
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 «Кабатлана ала язлар да...»
15.35 «Тел күрке – сүз»

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ХОЛЕСТЕРИН ЯШЬКӘ КАРАМЫЙ

Без аның начар якларын гына күрергә ияләнгән. Табиблар исә, аның файдасы да күп, дип искәртә. Сүзебез – холестерин турында. Ул күпме булырга тиеш? Холестеринның югары булуы куркынычмы? Ә кимесә, нишләргә?

Табиб-терапевт Гөлназ ШӘЙДУЛЛИНА шул сорауларыбызга җавап бирде.

:: Ни өчен без холестеринны дошман күрәбез?

– Чынлыкта холестерин – организм өчен бик кирәкле матдә. Аның яртысын организм үзе эшләп чыгара, калганы ашаган ризык белән керә. Ул D витаминны, җенес гормоннары эшчәнлегендә катнаша. Моннан тыш мускулларны тонуста тотарга да ярдәм итә. Шуңа күрә организм өчен билгеле бер күләмдә холестерин кирәк. Аның артып китүе генә куркыныч. Кандагы холестерин күләме 5,0 ммоль/л дан да югары булмаска тиеш. Шуннан артып китсә, холестерин кан тамырлары стеналарына сылана, органнарда кан йөрүне тоткарлый.

Холестерин – саннарда

✓ яхшы – **5 ммоль/л**
✓ аз гына югары – **5 һәм 6,4 ммоль/л** арасында
✓ уртача югары – **6,5 һәм 7,8 ммоль/л** арасында
✓ бик югары – **7,8 ммоль/л** дан югары

:: Соңгы арада яшьләр арасында да, холестериным югары, дип зарланучылар артып китте кебек...

– Өлкән яшьтәге кешеләрнең генә холестеринны арта дигән фикер бар. Чынлыкта вазгыять башкачарак. Холестерин арту яшькә карамый. Ул йөрәк чиреннән, артык авырлыктан, бавыр, бөер һәм калкансыман биз авыруларыннан интегүчеләр арасында ешрак очрый. Иммунодепрессант кебек кайбер төр дарулар эчкән чакта да кандагы холестерин күләме артырга мөмкин. Андый чакта кешене берни борчымаска да мөмкин. Шуңа күрә алда телгә алган чирләрдән интеккән кешеләргә холестеринны даими тикшертеп торасы.

:: Холестеринның артуы иң беренче чиратта нәрсәсе белән куркыныч?

– Кандагы холестерин күләме еш кына майлы ризык ашау, хәрәкәт җитмәү, тәмәке тарту, исерткеч эчемлекләр куллану кебек начар гадәтләр, артык авырлык пәйда булу аркасында күбәя. Юл югары булса, йөрәк-кан тамыры авырулары (инфаркт, инсульт) килеп чыгу куркынычы арта. Кан тамырлары да зарарланырга мөмкин. Моннан тыш холестеринның югары булуы калкансыман биз авыруы (гипотиреоз), бөер һәм бавыр эшчәнлегендә җитешсезлекләр барлыгы турында да кисәтә.

:: Холестеринның азаеп китүе нәрсәне аңлата?

– Холестерин зарарланган орган, тукыма һәм күзәнәкләрне «төзәтү»дә катнаша. Шуңа күрә аның нормадан түбән булуы организмда ялкынсыну башлану турында сөйли. Операция, стресс кичергән, респиратор, бактериаль чирләр белән авырган кешенең дә еш кына холестеринны түбәнәя. Ул азайганда бавырны да тикшертергә кирәк.

:: Холестерин артмасын өчен, йомыркадан баш тартырга кирәк, дип киңәш бирүчеләр дә бар.

– Әйе, кайберәүләр, холестерин күп булган ризыклардан баш тартса, шул итә, дип саный. Әмма бу – ялгыш фикер. Дөрестән дә, шул ук йомыркада холестерин бик күп. Әмма сау-сәламәт кешегә көнгә бер-ике йомырка ашауның бер зыяны да юк. Ит белән сөт тә – иң төп холестерин чыганаклары бит. Шул ук вакытта аларның организм өчен файдасы да бихисап. Шуңа күрә һәр нәрсәдә чама хисе булырга тиеш.

:: Холестеринны ничек тикшертеп торырга?

– Аны елга бер тапкыр тикшертү җитә. Диспансеризация профилактик тикшеренүләр вакытында да кандагы холестерин дәрәҗәсен ачыкларга мөмкин. Шуңа күрә табибка вакытында күренеп торырга кирәк. Ир-атлар – 35 яшьтән, хатын-кызлар 45 яшьтән узгач, холестеринны даими тикшертеп торырга тиеш.

vk.com

Исеңдә тот!

▶ Көн саен 2 кишер ашау ярты елда холестерин микъдарын 10–20 процентка киметә ала.
▶ Көн саен 1 бүлемтек сарымсак ашау кандагы куркыныч холестерин күләмен ярты елда 44 процентка азайтырга мөмкин.
▶ Көн саен 1 грейпфрут ашау ике айда холестерин микъдарын 6 процентка төшерә. Әмма әлеге җимешне ач карынга һәм дару эчәр алдыннан ашарга ярамый.
▶ Көн саен суган һәм сарымсак ашау да файдалы. Организм алардан кирәкле күләмдә биоактив матдәләр ала. Алар, үз чиратында, кан тамырлары стеналарына начар май төерләре укмашудан һәм ялкынсынудан саклый.
▶ Кипкән алма да файдалы. 75 грамм кипкән алма холестеринны 15–20 процентка киметә.
▶ Помидор, томат пастасы, томат согы, сардина, сайра, сельдь балыкларында холестеринны киметергә ярдәм итә.
▶ Холестерин югары булганда майлы ризыклардан баш тартырга кирәк. Бигрәк тә майонез, эремчек, камыр ризыклары, туңдырма, торт, кәнфит ише тәм-том ашарга киңәш ителми.

Киңәш-табыш

Ачы дәва

С витаминына иң бай җимеш саналган лимонның без белеп бетермәгән файдалы яклары бихисап.

☑ Әйтик, тамак шешкәндә телемләп киселгән лимон ашарга кирәк. Моны сәгать саен эшләү хәерле. Лимонны кабыгы белән ашыйсы. Тамак авырту басылачак.
☑ Ютәл вакытында бал, лимон суы һәм шикәр комыннан ясалган кайнатма файдалы.
☑ Томау төшкәндә борынга көнгә 5–6 тапкыр берничә тамчы лимон суы тамызырга кирәк.
☑ Баш авыртканда лимон кабыгының ак элпәсен әрчеп, юеш ягы белән чигәгә куеп торырга кирәк.

Үзем сынадым

КАВЫКТАН КОТЫЛДЫМ

Кавыкны бетерүнең җайлы гына ысулын таптым. Моның өчен 1 стакан кайнар суга 3 чәй кашыгы вакланган дәфнә яфрагы салып, ярты сәгать дәвамында төнәтергә кирәк. Аннары шуны сөзеп, чәч юганнан соң баш тиресенә сөртергә кирәк. Ахырдан чәчне чайкатмасаң да була. Төнәтмәне суыткычта сакларга кирәк.

Алсу ВАФИНА. Балтач

Белеп тор!

Кәефне дә күтәрә

Авырганда нәрсә ашау файдалы? Әлбәттә, тавык шулпасы! Операциядән соңгы чорда гына түгел, вируслы авырулар вакытында да шифалы ул. Бу хәтта фәнни яктан расланган.

Моннан тыш, тавык шулпасы сулыш юлларындагы лайланы чыгарырга ярдәм итә. Өстәвенә тавык ите цистеинга – аминокислотага бай, ул организмга вирусларга каршы торырга булыша.

Тавык итендә триптофан аминокислотасы да бар. Ул кәефне яхшырта. Тизрәк савыгу өчен анысы да кирәк!

Тавык шулпасы ялкынсынуны киметә, авыруны җиңеләйтә

һәм чиргә каршы көрәшергә көч бирә. Моннан тыш, ул организмда суга кытлык булдырмый.

Тавык шулпасы өреле булган саен, файдалы үзенчәлекләре күбрәк була, ди галимнәр. Ураза тотучылар өчен дә иң файдалы аш – тавык шулпасы.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина
СЕМЕНОВА

ҖЫЛЫ «ОЯ» ӘЗЕРЛИБЕЗ

vk.com

Теплицаны язга әзерләү – бакчачыларның төп мәшәкатьләреннән берсе. Булачак уңыш бу эшнең ни дәрәҗәдә дөрес башкарылуына бәйле. Кыштан соң теплицаны ничек эшкәртәсе?

«Россельхозцентр» оешмасы Татарстандагы филиалының үсемлекләрне саклау бүлеге әйдәп баручы агрономы Гөлия ГАЗИЗОВА шул хакта аңлатып үтте.

– Тәҗрибәле бакчачылар теплицага карны инде март башларында ук керткәндер. Бу эшне кар эри башлаганчы башкарып куярга кирәк. Соңгарак калынса, туфрак тиз кипшермәячәк һәм тиз генә чәчеп булмаячак. Ә кар кертү бик кирәк. Йомшак кар суы туфрак өстеннән артык тозларны юып төшерә, минераль тозларны эретә, кыскасы, үсемлекләрнең туклануы өчен уңайлы мохит тудыра.

▶ **ЮУ.** Ә инде теплицада кар эреп беткәч һәм көннәр тәмам җылыткач, үсемлекләрнең җылы «оя»сын яңа сезонга әзерли башларга кирәк. Иң элек стеналарын юып алабыз. Әйтик, гадәти чәй содасы эремәсе (бер чиләк суга 2 аш кашыгы сода нисбәтеннән) яки сабынлы-серкәле эремә (10 л суга 100 г чамасы кер сабыны һәм 1 чәй кашыгы серкә эссенциясе) белән. Мондый эремә чистартып кына калмый, бәлки җиңелчә генә дезинфекцияли дә әле.

▶ **ДЕЗИНФЕКЦИЯЛӘҮ.** Күкерт шашкасы гөмбәчек авыруларына, бактерияләр һәм корткычларга каршы иң нәтиҗәле көрәш чарасы булып санала. Парлары барлык почмаклар һәм кечкенә генә ярыкларга да үтеп керә чөнки. Дезинфекция өчен күпме күкерт кирәк булуы теплицаның зурлыгына бәйле (бу хакта тартмасында язылган булыр). Ләкин аны бик сак кулланырга кирәк. Башта барлык форточкаларны ябарга. Шуннан теплица уртасына янмый торган берәр әйбер өстенә шашканы куеп, филтәсен кабызырга да тиз генә теплицадан чыгып китәргә. Ишеген ябарга. Янудан туктагач, берничә сәгатьтән соң, форточкасын һәм ишеген ачып, теплицаны берничә көн җилләтергә.

Теплицаны шулай ук водород перекисе эремәсе (1:1 нисбәтендә суга 6–9 процентлы водород перекисе саласы), сүндерелгән известь (10 л суга 3 кг известь һәм 500 г бакыр купоросы таләп ителә) белән дә дезинфекцияләргә мөмкин.

▶ **ТУФРАКНЫ ӘЗЕРЛӘҮ.** Иң яхшысы – туфракны тулысынча алыштыру. Мондый мөмкинлек булмаса, һич югында туфракның өске катламын (10–20 см калынлыкта) алып, урынына уңдырышлы яңа туфрак кертү әйбәт. Моның өчен берәр өлеш чирәмле туфрак һәм елга комы, өч өлеш черемә яки компост, биш өлеш торф кирәк булыр.

Туфракның уңдырышлылыгын арттыру өчен, иртә язда теплица түтәлләренә горчица чәчеп, спанбонд белән каплап куярга мөмкин.

▶ **АШЛАУ.** Теплицадагы туфракка фосфорлы ашлама кирәк. Иң яхшысы – суперфосфат. Аны суда эретеп, кимендә өч тәүлек тотарга. Тонәтмәнең өсте белән туфракны ашларга. Бер квадрат метр мәйдандагы туфракка 30 грамм гади суперфосфат алырга кирәк. Ә инде «двойной» суперфосфат булса, шул ук мәйданга 20 грамм чамасы да җитә.

Моннан тыш язын фосфорит оны, калийлы ашлама (иң киң таралганы – калий сульфаты) кулланалар.

Ә инде туфракны корткычлардан һәм авырулардан саклауның иң җиңел ысулы – түтәлләргә кайнар су сибеп, өстен пленка белән каплап кую. Кайнар су авыру таратучы инфекцияне, йокалган бөҗәкләр һәм личинкаларны юкка чыгара.

Укучы хаты

ӨЧ АТНА АЛДАН ӨЛГЕРӘ

Кыяр орлыгын бер литрлы пластик стаканнарга (черемә тутырып) чәчәм. Һәрбер савытка, орлыктан тыш, берәр фасоль төртәм. Теплицага да икесен бергә күчереп утыртам.

Эш шунда: кыярга тиз үсү һәм уңыш бирү өчен бик күп азот кирәк. Ә фасоль, туфрактагы бактерияләр белән элемтәгә кереп, җирне азотка баета. Шулай итеп, икесен бергә утырту нәтиҗәсендә кыяр 2–3 атнага тизрәк өлгерә. Фасоле исә чөгендерле ашка китә.

Әлфинур НӘҖМЕТДИНОВА.
Казан

Тәмле булсын!

Сарымсаклы-сырлы аш

Бик тиз әзерләнелә торган искиткеч тәмле, затлы ризык.

Роза Гыйниятуллина рецепты

Кирәк: *1 баш эре сарымсак, 3 бәрәңге, 200 г эретелгән (өстәмәләрсез) сыр (плавленый сыр), 200 г каты сыр (пармезан яки башкасы), берничә петрушка ботагы, 1,5 л тавык шулпасы (башкасы да ярый), 3 аш кашыгы үсемлек мае, ярты чәй кашыгы төелгән борыч, багет (ак икмәк шакмаклары).*

Бәрәңгене әрчеп, шакмаклап турыйбыз. Сарымсакны әрчеп, тырнакларга аерабыз. Кәстрүл төбенә үсемлек мае белән сарымсакны салып, 1–2 минут чамасы кыздырып алабыз. Бәрәңге һәм шулпа өстәп, яшелчә пешеп чыкканчы утта тотабыз (13–16 минут). Ашка эретелгән сыр, тоз һәм борыч салабыз. Шуннан соң, блендер белән болгатып, боламык-аш ясыйбыз.

Каты сырны угыч аша чыгарабыз. Петрушканы ваклап турыйбыз. Багетны майсыз табада бераз гына киптереп алабыз. Ашны тәлинкәләргә бүлеп, һәркайсының өстенә уылган сыр һәм петрушка сибеп чыгабыз да багет белән ашыйбыз.

Белсәң, зыян итмәс

Төсле ачкыч

Бәйләмдә бер үк төрле ачкычлар күп булса, кирәклесен тиз генә таба алмыйча аптырыйсың. Мондый очракта һәрберсенең өске өлешен төрле төстәге тырнак лагына буяп куярга мөмкин. Төсне истә калдыргач, кайсының кайсы ишектән икәне бик җиңел аңлашылачак. Игътибар: буяганчы, ачкыч өслеген ацетонда чылатылган мамык диск белән ышкып алырга кирәк (тимерне майсызландыру өчен).

Яңа туфли кырса

Тәрәзә юу сыекчасы... яңа туфлине аякка иплерәк кереп утыртырга ярдәм итә. Аны аяк киеме эченә, аеруча кыса торган өлешләренә бөркегез. Шуннан соң, туфлине киеп, фатир эчендә берәр сәгать чамасы йөрегез. Кирәк булса, тагын бер тапкыр шулай эшләгез. Бу очракта яңа аяк киеме, кысып яки кырып, кәефегезне төшермәячәк.

Кирәге чыгар

ТӨТЕН ЮЛЫ

Мунча миче торбасына корым утырса, утын начар яна. Төтен юлын чистарту өчен, мичкә ягып җибәргәндә, утын белән бергә, бераз гына бәрәңге кабыгы салырга мөмкин. Болай эшләгәндә, морҗа бик әйбәт суырачак.

КАБУЛ КЫЛСЫН

Сәдаканың берничә төре, шулар арасында мәҗбүри саналганнары бар. Ул да булса – зәкят, гошер, фитыр. Рамазан аенда мөселманнарның аеруча да фитыр һәм фидия сәдакалары турында сораулары күп җыела. Бу сәдакаларның билгеле күләме бармы? Әлеге сәдакаларның әҗере нинди? Аларны кемгә тапшырырга мөмкин?

«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН шул һәм башка кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

:: Фитыр һәм фидия сәдакалары турында аңлатып үтсәгез иде.

– Аллаһның рәхмәте белән рамазан ае килүгә, гаеткә кадәр без фитыр сәдакасын тапшырабыз. Бу сүз «чистарыну» дигәнне аңлата. Хәтта ананың йөрәк астында йөргән бала өчен дә фитыр сәдакасы бирелергә тиеш. Ураза тоткан вакытта без начар гамәлләр кылырга мөмкинбез. Әйтик, кем беләндер ачуланышырга. Шулардан котылу, чистарыну өчен, фитыр сәдакасын тапшырабыз. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Кем дә кем гаеткә кадәр фитыр сәдакасын бирсә, ул фитыр сәдакасы дип саналыр, һәм безнең хата-кимчелекләребезне, гөнаһларыбызны Аллаһы Тәгалә гафу итәр».

Фидия сәдакасына килгәндә, ул – картлык яисә чир аркасында ураза тота алмаган кешенең сәдакасы. Ягъни ураза тотмаган көннәр өчен башка кешене ашатырга тиеш булабыз. Уразаны алмаштыру дип тә атарга була. Фидия мохтаҗларга ярдәм күрсәтү санала. Бу төр сәдаканы алгач, башка кешеләргә бирергә, башка максатлар өчен тотарга рөхсәт ителми.

:: Аларның күләмнәре нинди?

– Диния нәзарәте аны ел саенраслый. Нәзарәтнең Голәмәләр Шурасы һәм Казыйлар Шурасы карары белән, быел фитыр сәдакасын түләү өчен нисаб күләме – 43000 сум (көмеш буенча), зәкят чыгару өчен нисаб күләме 495000 сум (алтын буенча) билгеләнде. Фитыр сәдакасы арпа буенча исәпләгәндә – 150 сум, йөзем белән исәпләгәндә – 1000 сум. Фидия – 400 сум.

:: Бу сәдакаларны кайчан бирергә?

– Фитыр сәдакасы гаеткә якынрак булган көннәрдә тапшырылса, хәерлерәк. Фидия исә ураза дәвамында бирелергә тиеш.

:: Бу сәдакаларны тапшырганда дога укыйсымы?

– «Йә, Раббым! Алучыдан да, бирүчедән дә кабуллардан кыл!» – дисәк тә хәерле булыр.

:: Фитырны азык-төлек белән тапшырырга рөхсәтме?

– Ярый, әлбәттә. Рәсүлебез (с.г.в.) үзе дә ризыклата биргән аны. Әйтик, ул якынча 3 л банка күләмендә хөрмә бирә торган булган. Без дә, җәмәгать, карабодай, дөге һәм башка азык-төлек җыеп, пакет туплап, мескен кешегә бирсәк, начар булмас.

:: Фитыр сәдакасын мәдрәсә-мәчетнең матди ихтыяҗлары өчен бирергә ярыймы?

– Әлбәттә, мәчетләр бу сәдакаларны җыя. Әмма без аны мескен-ятимнәргә таратабыз.

ФИТЫР СӘДАКАСЫН КЕМГӘ ТАПШЫРЫРГА?

Рөхсәт ителми	Рөхсәт ителә
Әти-әниләргә, аларның әти-әниләренә, әби-бабаларның әти-әниләренә һ.б.	Мөселман кеше үз абыйсына (энесенә) һәм апасына (сеңлесенә) бирә ала
Балаларыңа, балаларыңның балаларына, оныкларның балаларына һ.б.	Фәкыйрь, мохтаҗ, аз керемле кешеләргә
Үз гаиләңә	Акча эшли алмаган авыру кешеләргә
Мәчет чыгымнарына (ут, су, газга)	Күпбалалы гаиләләргә
	Бик күп бурычы булганнарга
	Пенсия акчасына гына яши алмаган әбиләргә, бабайларга

ФИТЫР СӘДАКАСЫН КЕМ БИРӘ?

Балигъ булган, мохтаҗлык кичермәгән, акчалата бурычы булмаган һәр мөселман (ураза тотамы, юкмы – мөһим түгел).
Мөселман фитыр сәдакасын, үзеннән башка, ислам буенча кече яшьтәге (балигълыкка җитмәгән) балалары өчен дә таратырга тиеш. Мөселманга фитыр сәдакасын хатыны, ата-анасы яки балигълыкка җиткән балалары өчен бирү мәҗбүри түгел. Чөнки ул аларның милкенә дәгъва итә алмый. Әмма мөселман, теләге булганда, бу кешеләр өчен фитыр сәдакасын бирә ала.

** dumrt.ru мәгълүматларына таянып*

ru.freepik.com

Сорау – җавап

Хәзрәт җавап бирә

Көндәлек тормышыбызда күңелне борчыган сораулар туып кына тора. Араларында дингә кагылышлылары да байтак. Шуны истә тотып, сәхифәбездә яңа рубрика башлап җибәрәбез. Дингә кагылышлы соравыгыз булса, аны 89534975861 («Ватсап») аша безгә юллый аласыз.

Укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИНОВ җавап бирә.

? Тәһарәтне иртән алгач, оекбаш киеп куйсаң, аякны бүтән юмаска була, хәтта сәфәргә китсәң, өч көн юмаска да була, диләр. Мәчеттән алган китапта шулай язылган. Аңлатма бирсәгез иде!

Наилә НАСЫЙБУЛЛИНА

– Динебез тарафыннан мөселман бәндәсенә шундый җиңеллек бирелгән, ул да булса, аякларны юмыйча, аякка кигән киемгә мәсех кылып, гыйбадәт башкару мөмкинлеге. Әмма бу гамәл дөрес булсын өчен, шартларын дөрес итеп үтәргә кирәк.
Киемгә бәйле беренче шарт: бу кием тиредән (күннән) ясалган булырга тиеш. Гади генә оекбаш, суны сеңдерә торган, аякка су үтеп керә торган бернинди аяк киеме мәсех кылу өчен рөхсәт ителми. Икенче шарт: аякка киелгән кием тубыкларны капларга тиеш. Өченче шарт: аякка киелгән кием намазда үтәлә торган хәрәкәтләргә киртә булырга тиеш түгел. Гади итеп әйтсәк, мәсех кылыначак киемнең табаны каты, бөгелми торган булмаска тиеш. Әлеге шартларга туры килгән аяк киеменә генә мәсех кылу рөхсәт. Мондый аяк киемен без читек дип атыйбыз.

? Мин тәһарәтле килеш читек кидем. Аннан бәдрәфкә бардым. Тәһарәт алдым, читеккә мәсех кылдым. Бераздан читекне салдым. Сорау шул: миңа тәһарәтне тулысынча алыргамы яисә аякны гына юсам да буламы? Мин бит тәһарәтле, аякка гына мәсех кылган идем.

Роза МӨХЕТДИНОВА

– Тәһарәт бозылмаган хәлдә, ялгыш яисә кешенең үз ихтыяры белән аякка киелгән читекләр салына икән, бу очракта тәһарәтне тулаем алу шарт түгел. Аякларны юып, читек киеп, аңа мәсех кылу нияте белән, иң азакта шуларга мәсех кылу рөхсәт ителә. Гади итеп әйтсәк, аякларны юып, читек кию җитә.

? Хатын-кызга хаҗдан соң чәчләрен күрсәтергә ярыймы?

Шәүкәт ГАЙНАНОВ

– Дин күзлегеннән чыгып әйткәндә, хаҗга кадәр дә, хаҗдан кайткач та, аермасы юк. Хатын-кызның, балигълыкка җиткән кызның чит ир-атлар янында чәчләре капланган булырга тиеш.

Хикмәтле сүз

«Аллаһы беркемгә дә көченнән килмәслек нәрсә йөкләми».
«Әл-Бәкара/Сыер», 2:286

«Әгәр үлемнән яки үтерелүдән качсагыз [әҗәлегез җиткән булса], бу качу сезгә файда китермәячәк».
«Әл-Әхзәб/Гаскәрләр», 33:16

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Бик беләсегез килсә...

...җырларда яңгырый торган кеше исемнәре «хук» дип атала. Гадирәк әйтсәк, җырны истә калдырырлык итү өчен кулланыла торган алым була ул. Хәтерләсәгез, газетабызның узган санында бу турыда сөйләшә башлаган идек. Дәвам иттерик.

Хук («hook») ул – җырның «эләктереп» ала һәм истә кала торган бер өлеше. Эзләсәң, аны табылган һәр җырда табарга була.

Бу юлы кеше исемнәре, аерым алганда, хатын-кыз исемнәре кергән җырларны барлыйк. Шактый алар! Мәхмүт Хәсәен сүзләре, татар халык көенә иҗат ителгән «Өммегөлсем»не белмәгән кеше юктыр? Һәрхәлдә, «Бас, әйдә, Өммегөлсем...» дигән өлешен җырлап бирә аласыз инде. «Сафия такмаклары» да һәркемгә таныш. «Сафия, кара әле / Алда гомер бар әле», – дип кем җырламаган?! Татар халык җырларыннан «Мәдинәм, гөлкәем» бар әле. Безнең халык «хук»ларны шәп кулланган, кыскасы.

Мәшһүр җырчы Рәшит Ваһапов репертуарын барладым. Хатын-кыз исемнәре кергән иң күп җырлар анда булган икән! «Ал Зәйнәбем», «Асылъяр», «Галиябану», «Зөләйха», «Нурия», «Фирдәвескәй», «Хафизәләм, иркәм»... Санап бетерерлек түгел.

Ә Салават Фәтхетдинов әнә ерак китеп тормаган: «Абый, абый, Салават абый...» – дип җырлый.

Аннан-моннан

Узып баручы атна нiләр белән истә калачак? Бу сорауга җавап итеп социаль челтәрләрдәге «кайнар» яңалыкларны тупладык.

Илназ Гарипов өйләнгән. Элек шактый популяр булып, хәзер югалып торган җырчы «камыт» кигән. 30ын шактыйдан тутырган Илназның өйләнүен белгәч, куплэр: «Ниһаять!» – дип куйды. Яшьләргә бәхет телик!

Милли китапханә сәхнә артын күрсәтә. 15 марттан 26 майга кадәр Татарстан Милли китапханәсенең күргәзмәләр залында «Сәхнә артындагы тормыш. Үткәннән киләчәккә» күргәзмәсе эшләячәк. Анда бутафория, театр костюмнары, грим эскизлары һәм фотосурәтләрне күреп булачак. Күргәзмә Казан театр училищесындагы сәнгать юнәлешенә нигез салынуның 60 еллыгына багышланган.

Татар кызы – прима-балерина! 7 мартта Мария театрындагы «Шүрәле» спектакленнән соң татар кызы Рената Шакированы прима-балерина дип игълан иттеләр. Ташкентта туган Ренатаның репертуарында 20ләп роль бар.

Ришат Төхвәтуллинның гримеркасын туздырганнар. Уфадагы гастрольләре вакытында булган бу хәл. Төркемнең барлык әйберләре дә калган гримерканы төнлә туздырып чыгып киткәннәр. Хәтта кайбер әйберләрен урлаганнар да. Алия белән икесенең бүлмәсенә керә торган җиргә инә кадап чыгып киткәннәр. «Миңа «бу – хайп» дип яза башладылар. Хайп түгел, дуслар, минем беркайчан да хайп белән шөгыльләнгәнем булмады», – ди Ришат.

ИЛНАР СӘЙФИЕВ: «ЭСТРАДА КЫЙММӘТЛӘНГӘН»

Аның «Талбишек» җырын ишетмәгән, белмәгән татар юктыр. Алты-җиде ел буе югалып торган Илнар СӘЙФИЕВ – тамашачысын, ә тамашачысы Илнарны бик сагынган. Җырчы сәхнәдән китүенә үкенәме? Ә кайтырга нәрсә этәргән?

:: Соңгы концертыгыз 2017 елда булган. Шуннан соң сез кинәт кенә юкка чыктыгыз. Бу еллар эчендә тормышыгыз ничек үзгәрде?

– 2017 елда игезәкләребез туды. Сәхнәдән югалып торуымның сәбәбе –балаларымның үскәнен күрәсе килү. Хатыныма да үзенә генә бик авыр иде, аңа ярдәм иттем. Озак көтеп алынган сабыйларыбыз ул.

:: Өч бала әтисе булу авырмы?

– Авырлык түгел, җаваплылык ул. Күпбалалы гаиләләр аңлар мине: алар шау-гөр килеп торган чакта, булган авырлыклар онытыла кебек.

:: Сез үзегез бик яшьли әтисез калгансыз. Балаларыгызның үскәнен күреп калырга тырышу шуңа да бәйле түгелме икән?

– Анысы да бардыр. Әти назы, әти кочагы, әти кулы бик кирәк балага. Миңа – 12, энем Ленарга 8 яшь булган вакытта әтисез калдык. Иң кирәк чагында китеп барды ул. Хәер, әти гел кирәк! Мин әле аны яхшы хәтерлим. Аның каешы да, киңәше дә әлэкте миңа. 7–8 яшемдә аның белән балта тотарга, эштән курыкмаска өйрәндем.

:: Сәхнәгә нәрсә кайтарды?

– Мине күргән, таныган кешеләр һәрвакыт: «Илнар, нигә җырламыйсыз? Сезнең сөйкемле сәгегез бар, тавышыгыз матур!» – дия килде. Болай да янган йөрәккә ут өстәп. Дөресен генә әйткәндә, урыным сәхнәдә булуын белә идем мин. Бу еллар дәвамында алкышларны, тамашачымны бик сагындым. Сәхнәдә җырлау миңа көч бирә иде.

:: Популяр чакта сәхнәдән китү авыр булгандыр. Үкенмәдегезме?

– Үкендем. Бик авыр булды. Үземне эчтән ашадым.

:: Эстрадада нiләр үзгәргән соң?

– Санап бетереп булыр микән аны? Җырларның яңгырашыннан алып сәхнә бизәлешенә кадәр бөтен нәрсә үзгәргән. Иң күзгә ташланганы – бәяләр шактый күтәрелгән. Җырлар яздырам, артист булам дисәң, кеременә дә шактый яхшы булырга тиеш. Эстрада кыйммәтләнгән.

Миңа: «Илнар, син сәхнәгә бик вакытлы кайтасың», – диләр. Халыкта элеккене сагыну хисе көчле хәзер. Соңгы арада мин берничә җырымны яңартып чыгардым. «Без бит бу җыр белән үстек», «Бу җырны яттан беләбез», «Балачакка кайткан кебек булдым» ише сүзләрне еш ишетәм. Элеккеге хитлар да, яңа җырларым да апрельдә узачак концертымда зур сәхнәдән яңгыраячак.

:: Ә эстрададагы мөнәсәбәтләр үзгәргәнме? Әйтик, элек җырчылар арасында дуслык бар идеме, хәзер бармы ул?

– Үзгәргән. Көнчелек, бер-береңне хәтта күралмау арткан. Көндәшлек башка форма алган дип әйтимме соң. Ә дуслыкка килгәндә, шәхсән мин элек барысы белән дә дус идем. Хәзер бик сирәкләр белән аралашам. Элек җыр чыккан саен шалтыратып, минем өчен сөенүчеләр бар иде.

> Эстрадада гына түгел бу хәл. Кешелек, дөнья үзгәрде. Элек бердәмлек көчлерәк иде.

:: Сездәге үзгәрешләр турында да әйтми булмас. Сәхнәгә тышкы яктан үзгәреп, ябыгып кайттыгыз. Бу махсус эшләндеме?

– Беренче чиратта, үзем һәм сәламәтлегем өчен. Өч баламны, алар алдында җаваплы булуымны уйладым. Үзем дә әтисез калгач, уйландыра икән ул. Яшисе килә! Аннан соң, мин шактый гына элеккеге чыгышларымны карадым. Тышкы кыяфәтемнән канәгать буласым, сәхнәгә яңарып кайтасым килде.

:: Сезне нинди җыр аша беләләр?

– «Талбишек», билгеле. Ул – халкыбызның йөзек кашы, тарихыбыз, һәркайсыбызның башлангычы. Кызганыч, хәзер бишекләребезне коляскалар алыштырды. Ә бит ул – төрки халыкларны берләштерүче әйбер. Кайсын гына алма, өй түрләрендә бишек эленеп торган.

:: «Талбишек» – Роберт абый Миңнуллин сүзләренә иҗат ителгән җыр. Репертуарыгызда аның шактый җырлары бар дип беләм.

– Әйе, җырларымның 70–80 проценты Роберт абый сүзләренә язылган. Иҗатымның башлангыч чорыннан ук аралашып, дус булып яшәдек. Ул мине Илнар Сәйфиев булганчы ук белә иде. Бу турыда моңарчы сөйләгәнем булмады. Шулай бервакыт без үскән Тукай районының Биклән авылына Роберт Миңнуллин килде. Аның «Энекәш кирәк миңа» китабын яттан диярлек белгән чагым иде ул. Укытучы, актлар залында узачак очрашуда җырларга кирәк, диюгә, иң беренче кулымны мин күтәрдем һәм Роберт абый алдында җырладым. Аның, җилкәмнән сөеп: «Энекәш, киләчәктә зур уңышларга ирешәсең әле син», – дигән сүзләрен мәңге онытмам. Ул да мине онытмаган. Җырлый башлаган чорымда, «Талбишек»не яздырып йөргәндә, очрашкач, «Хәтерем ялгышмаса, минем сине Тукай районының Биклән авылында күргәнем бар бит», – диде ул. Роберт абый белән соңгы көннәренә кадәр аралашып торуым белән бәхетле мин.

:: Их, бүген шундый авторлар җитми, дигән уйлар килмиме?

– Роберт абый кебек кеше юк һәм булмас та инде ул. Чыннан да, сәләтле, өметле авторлар аз хәзер.

:: Һәм, ахырдан, сезнең өчен бүген тормышта иң мөһиме нәрсә?

– Сәламәтлек. Бар нәрсә дә бар заманда яшибез. Ләкин саулык булмаса, берсе дә кирәк түгел.

ӘҢГӘМӘНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

20 март | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
11.00, 00.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ИСЕМЕМ ЦЗЮНЬ ЦЗЮ ЛИН» 16+
13.00, 00.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кызган казан» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «НИТИ ЛЮБВИ» 12+
01.15 «Кәмит Җәвит» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
10.00 «Халкым минем» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Сөйләшергә вакыт» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Кәмит Җәвит» 16+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
04.20 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «Под небом Крыма» 12+
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.45, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ПЕРЕВЕДИ ЕЁ ЧЕРЕЗ МАЙДАН» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Шоу Вована и Лексуса» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ВАСНЕЦОВА» 12+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
03.40 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «География спорта» 12+
07.00, 09.30, 15.55 Новости
07.05, 13.00, 16.00, 21.55, 00.45 Все на Матч!
09.35, 04.00 Лыжные гонки. Альфа-Банк Чемпионат России
12.40 Специальный репортаж 12+
13.25, 01.25 «Вид сверху» 12+
13.55 Хоккей с мячом. Чемпионат России. Финал
16.45, 19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/4 финала
22.35 Дартс. OLIMPBET Международная лига. Тур 2
01.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Руна» – «Астана» 6+

НТВ

04.55 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. МОРЕ И ГОРЫ» 12+
22.10 «ПРЕТОРИАНЕЦ» 16+
00.45 «ПОД ПРИКРЫТИЕМ» 16+
02.40 «ДОЗНАВАТЕЛЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.30, 04.20 «Давай разведёмся!» 16+
08.30, 02.40 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.05 «Понять. Простить» 16+
11.55, 00.15 «Порча» 16+
13.00, 01.15 «Знахарка» 16+
13.35, 01.50 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ДВА КРЫЛА» 16+
02.15 «Голоса ушедших душ» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «ШОФЕР ПОНЕВОЛЕ» 12+
13.25, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.45, 03.25 «АНДРЕЕВСКИЙ ФЛАГ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ГАИШНИКИ» 16+

21 март | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «ИСЕМЕМ ЦЗЮНЬ ЦЗЮ ЛИН» 16+
13.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Азбука долголетия» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.10 «Свенеч» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30, 01.15 «Точка опоры» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Наши герои» 16+
22.10 «Безнең Республика – безнең гамәл» 16+
00.00 «НИТИ ЛЮБВИ» 12+
00.50 «Видеоспорт» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00, 20.00 «Кызган казан» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «Под небом Крыма» 12+
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.45, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ПЕРЕВЕДИ ЕЁ ЧЕРЕЗ МАЙДАН» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.10 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ВАСНЕЦОВА» 12+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
03.40 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 10.05, 15.50 Новости
07.05, 13.00, 14.10, 15.55, 21.55, 00.20 Все на Матч!
10.10 «Шумахер и Шумахер» 12+
10.55, 12.10 Бобслей и скелетон. Чемпионат России
11.50 Специальный репортаж 12+
15.20, 01.25 «Большой хоккей» 12+
16.45, 19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/4 финала
22.35 Смешанные единоборства. UFC. Пётр Ян 16+
00.55 Фрирайд. Мировой тур 6+
01.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Локомотив-Кубань» – «ПАРМА» 6+
04.00 Дартс. OLIMPBET Международная лига. Тур 2 0+

НТВ

04.55 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. МОРЕ И ГОРЫ» 12+
22.10 «ПРЕТОРИАНЕЦ» 16+
00.55 «Поздняков» 16+
01.10 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
02.05 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
02.35 «ДОЗНАВАТЕЛЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.15, 04.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.15, 02.45 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.10 «Понять. Простить» 16+
11.40, 00.20 «Порча» 16+
12.55, 01.20 «Знахарка» 16+
13.30, 01.55 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «КОГДА ЛЮБОВЬ СОВСЕМ НЕ ЖДЁШЬ» 16+
02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 03.15 «ВЗРОСЛЫЕ ДЕТИ» 12+
12.35, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.25, 19.55 «По горячим следам» 16+
13.45, 04.30 «АНДРЕЕВСКИЙ ФЛАГ» 16+
15.00 Военные новости 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ГАИШНИКИ» 16+

22 март | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Наши герои» 16+
14.45 «Семь дней +» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Родная земля» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Юлчы» 16+
22.10 «КВН РТ-2024» 16+
22.40 «БЫТЬ ФЛИННОМ» 16+
00.30 «Семь дней+» 16+
01.00 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
01.15 «ТАМАК» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 02.00 «Заман көзгесе» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 01.05 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
19.10, 22.15, 02.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Родная земля» 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
03.30 «Мин кайтырмын сезгә яңадан...» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «Под небом Крыма» 12+
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.45, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос» 12+
23.55 «Матадор» 16+
00.55 «ВСЁ ПРОШЛО ХОРОШО» 18+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Судьба человека» 12+
16.30 «Прямой эфир» 16+
21.30 «Удивительные люди» 12+
23.55 Церемония вручения музыкальной премии «Виктория»
02.10 «ПОД ПРИЦЕЛОМ ЛЮБВИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 09.10 Новости
07.05, 14.30, 21.55 Все на Матч!
09.15 «Небесная грация» 0+
09.35 Лыжные гонки. Альфа-Банк Чемпионат России
13.55 Бобслей и скелетон. Чемпионат России
15.30 Смешанные единоборства
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/4 финала
22.45 Бокс. Bare Knuckle FC
01.00 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
01.30 «География спорта» 12+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС – «Зенит» 6+
04.00 Дартс. OLIMPBET Международная лига. Тур 2 0+

НТВ

04.55 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. МОРЕ И ГОРЫ» 12+
00.00 «Своя правда» 16+
02.05 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
02.35 «Квартирный вопрос» 0+
03.25 «ДОЗНАВАТЕЛЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.25, 04.50 «Давай разведёмся!» 16+
08.25, 03.10 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.40 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.50 «Порча» 16+
12.55, 01.50 «Знахарка» 16+
13.30, 02.15 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «МЫ ЭХО ДРУГ ДРУГА» 16+
23.10 «Уютное утро» 16+
02.45 «Голоса ушедших душ» 16+
05.40 «6 кадров» 16+
06.05 «И СНОВА БУДЕТ ДЕНЬ» 16+

ЗВЕЗДА

09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.20 «Ищу своих» 12+
10.10 «СКАЗ ПРО ТО, КАК ЦАРЬ ПЕТР АРАПА ЖЕНИЛ» 12+
12.20, 13.25 «ОТРЯД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
14.30 «ВИКИНГ-2» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.40 «Загадки века» 12+
20.30 «Скрытые угрозы» 16+
21.20 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 «Музыка+» 12+
00.55 «МОЙ ЛАСКОВЫЙ И НЕЖНЫЙ ЗВЕРЬ» 12+
02.45 «МЫ ЖИЛИ ПО СОСЕДСТВУ» 12+

23 март | Шимбә

ТАТАРСТАН
08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00, 03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Әдәби хәзинә» 6+
11.30, 01.10 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 «Созвездие – Йолдызлык-2024» 6+
15.00 «Рифат Зарипов – 35!» 12+
17.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
18.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «ХОТЕЛ БЫ Я БЫТЬ ЗДЕСЬ» 12+
23.50 «ГОД ТЕЛЁНКА» 12+
01.35 «ТАМАК» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 16+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.05 «Гомер тәлгәшләре» 12+
17.15 «Казаннан – казанга» 16+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Гомер китабы» 16+
23.10 «СИҢА КАЙТАМ» 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ
06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Наше всё» 12+
11.05 «ПроУют» 0+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «ШИРЛИ-МЫРЛИ» 16+
15.50 «Ералаш». Детство строгого режима» 12+
16.55 «Я люблю мою страну» 0+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Эксклюзив» 16+
19.10 «Михаил Задорнов: вся жизнь» 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Клуб Веселых и Находчивых». Высшая лига 16+
23.50 К 135-летию со дня рождения Александра Вертинского 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.50 «В кругу друзей»
12.50 «Доктор Мясников» 12+
14.50 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «Я ОБЕЩАЮ МОЛЧАТЬ» 16+
00.55 «УЧИЛКА» 12+
04.20 «МОЙ БЕЛЫЙ И ПУШИСТЫЙ» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 Смешанные единоборства. One FC. Суперлек Киатмукао против Такеру Сегавы 16+
07.00, 13.40 Новости
07.05, 13.45, 19.25, 23.00 Все на Матч!
08.30 «Команда МАТЧ» 0+
08.35, 12.15, 00.00 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России
10.20, 04.00 Лыжные гонки. Альфа-Банк Чемпионат России
14.15, 16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/4 финала
20.55 Футбол. Товарищеский матч. «Црвена Звезда» – «Зенит»
02.00 Фехтование. Международный турнир «Московская сабля» 0+
05.00 Смешанные единоборства. UFC. Аманда Рибас против Роуз Намаюнас

НТВ
04.55 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.20 «Жди меня» 12+
07.20 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Основано на реальных событиях» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
19.00 «Центральное телевидение»
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Звезды» 16+
23.00 «Международная пилорама» 18+
23.45 «Квартирник НТВ у Маргулиса» 16+
01.00 «Дачный ответ» 0+
01.50 «ДОЗНАВАТЕЛЬ» 16+

ДОМАШНИЙ
09.55 «Уютное утро» 16+
10.30 «НАЧАТЬ СНАЧАЛА» 16+
14.45 «Я ВЕРНУСЬ ЗА ТОБОЙ» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
23.30 «АРЕНА ДЛЯ УБИЙСТВА» 16+
03.00 «6 кадров» 16+
03.25 «НАПАРНИЦЫ» 16+

ЗВЕЗДА
05.10 «НЕСКОЛЬКО ДНЕЙ ИЗ
04.00 «ОБЫКНОВЕННОЕ ЧУДО» 12+
06.20, 04.20 «ТАМ, НА НЕВЕДОМЫХ ДОРОЖКАХ…» 6+
07.55 «Морской бой» 6+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.20 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
11.10 «Мужики» 16+
11.40 «СССР. Знак качества» 12+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «Легенды науки» 12+
14.00 «Главный день» 16+
14.50 «Время героев» 16+
15.10 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШЕРЛОКА ХОЛМСА И ДОКТОРА ВАТСОНА» 12+
23.10 «ФАРТОВЫЙ» 16+
01.10 «СКАЗ ПРО ТО, КАК ЦАРЬ ПЕТР АРАПА ЖЕНИЛ» 12+
02.50 «ОПАСНО ДЛЯ ЖИЗНИ!» 12+

24 март | Якшәмбе

ТАТАРСТАН
08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 00.50 «Пар алма» 12+
08.00, 13.00 «Адымнар» 16+
08.30 «Тамчы-шоу» 0+
09.00 «Сөенеч» 0+
09.05 «Әти һәм мин» 0+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Тархан» 6+
11.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.40 «Татар сүзе» 12+
14.00 «Созвездие – Йолдызлык-2024» 6+
15.00 «Безнең Республика – безнең гамәл» 16+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней» 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
21.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.00 «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ ПОЗНАЛ БЕСКОНЕЧНОСТЬ» 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00, 02.45 «Шаян хәлләр» 16+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 «Венера йолдызлыгында» 16+
14.30 Татарстанның халык артисты Зөфәр Хәйретдиновның юбилей концерты 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.50 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ» 16+
01.05 «Манзара» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ
06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 «Жизнь других» 12+
12.15 «Повара на колесах» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.50 «КОГДА ДЕРЕВЬЯ БЫЛИ БОЛЬШИМИ» 12+
16.45 «Большая история» 16+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
23.00 «Что? Где? Когда?» 16+
00.10 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
06.10, 01.05 «ЧУЖИЕ ДЕТИ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
12.00 «Большие перемены»
13.00 «ВСЁ, ЧТО ЗАХОЧЕШЬ» 12+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

МАТЧ ТВ
08.00, 08.30, 13.40 Новости
08.05, 16.25, 23.00 Все на Матч!
08.35, 12.15, 00.00 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России
09.50, 04.00 Лыжные гонки. Альфа-Банк Чемпионат России
13.05, 01.30 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
13.45, 16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/4 финала
19.25 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Динамо» – «Химки»
21.30 Смешанные единоборства. UFC 16+
02.00 Фехтование. Международный турнир «Московская сабля» 0+
05.00 Бобслей и скелетон. Чемпионат России 6+

НТВ
04.50 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Маска» 12+
00.00 «Звезды сошлись» 16+
01.35 «Основано на реальных событиях» 16+
03.05 «ДОЗНАВАТЕЛЬ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.35 «АРЕНА ДЛЯ УБИЙСТВА» 16+
10.20 «Пять ужинов» 16+
10.35 «НЕЛЮБОВЬ» 16+
14.30 «ПОКА ПРОШЛОЕ НЕ РАЗЛУЧИТ НАС» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
00.00 «И СНОВА БУДЕТ ДЕНЬ» 16+
03.30 «НАПАРНИЦЫ» 16+

ЗВЕЗДА
05.30 «ЛАРЕЦ МАРИИ МЕДИЧИ» 12+
07.20 «ОТРЯД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Легенды армии» 12+
11.30 «Моторы и колеса» 12+
12.20 «Война миров» 16+
13.10 «Код доступа» 12+
14.00 «48 часов под огнем» 16+
14.50 «Скрытые угрозы» 16+
15.40 «Секретные материалы» 16+
16.30 «Загадки века» 12+
17.20 «Специальный репортаж» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.55 «СОБАЧЬЕ СЕРДЦЕ» 12+
02.20 «ПЕРВЫЙ ТРОЛЛЕЙБУС» 12+
03.45 «ВИКИНГ-2» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректораты каршындагы референты, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең Ветераннар советы рәисе **Терентьева** Ирина Васильевна; Татарстан Республикасының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Франция Республикасындагы вәкаләтле вәкиле **Йосыпов** Искәндәр Усман улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары ассоциациясе президенты **Байтемиров** Камиър Мижагит улы, театр сәнгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Гайнуллина** Алсу Әскәр кызы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр балалар поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Инвалид балаларны тернәкләндерү-дәвалау үзәге мөдире – табиб-невролог **Абдрахманова** Ләйсән Илдус кызына, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе Чаллы шәһәре, Актаныш, Тукай, Минзәлә районнарында территориаль бүлеге башлыгы **Бариев** Илгизәр Габделхаликъ улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең диагностика бүлекчәсе табиб-педиатры **Зәйнетдинова** Мәдинә Шиһап кызына, Казан шәһәренең «12 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының поликлиника эше буенча урынбасары **Наумова** Людмила Васильевнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы онкология бүлекчәсе мөдире – табиб-гематологы **Осипова** Илсөя Вагыйзь кызына, «ИМИН КЛИНИКАСЫ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең медицина консультанты, табибы – травматолог-ортопеды **Рябчиков** Илья Владимировичка, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе Алабуга, Әгерҗе, Менделеевск районнарында территориаль бүлеге башлыгы **Салихова** Роза Җәүдәт кызына, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең неврология бүлекчәсе мөдире – табиб-неврологы **Яковлева** Людмила Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Домкор Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең техник контроль бүлеге башлыгы урынбасары (Чаллы шәһәре) **Нестерова** Зоя Михайловнага, «Б.И. Тихомиров исемендәге «Казан Гипрониавиапром» акционер җәмгыяте генераль директоры **Садриев** Илнур Шафикъ улына, «Төзүче ТК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең балта осталары бригадиры (Зеленодольск шәһәре) **Шәмсетдинов** Габдулхәй Габдулла улына, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге матди-техник тәэминат идарәсе башлыгы урынбасары **Перова** Наилә Айрат кызына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сәрия
МИФТАХОВА

АЕК АВЫЛ

ИКЕ БАСУ АРТАШЫ ТОРМЫШ ФӘЛСӘФӘСЕ

Кибетендә хәмер сатмыйлар, чөнки эчүче юк. Эчмәгәч, эшкә дә, гаиләгә дә вакыт җитә. Саба районының 125 хуҗалыклы Ике Басу Арташы авылында гаиләләрнең нык булуын әнә шулай аңлаталар. Узган ел бирегә 8 бала дөньяга аваз салган. Аек яшәү рәвеше алып барган әлеге авылны без дә барып күрдек.

Нинди матур авыл! Наратлы, чыршылы таулар кочагына сыенган Ике Басу Арташын күргәч, «ВТ» журналистларының беренче сүзе шул булды. Тик исемен әйткәндә, чит кешегә бераз катлаулырак. Үзләре иярләнгән инде. Тарихы болайрак: бу сала ике авыл кушылудан, ике басудан барлыкка килгән. Бу урында Арташ авыл җирлеге башлыгы Алмаз Әгъләмҗанов болай ди: «Ник шулай кушканнардыр? Арташ кына булса, гадирәк бит. Ялы Арташ дигәне дә бар әле».

Төзек, заманча йортларыннан тырыш хуҗалар яшәве күренә. Тәрәзә йөзлекләре дә игътибарны җәлеп итә. Өч йөздән артык кеше яши монда. Клубы, бакчасы, ике кибете булса да, оптимальләштерү җилләре урап узмаган: унбер ел элек башлангыч мәктәпне япканнар. Шул сәбәпле егерме бер укучыга күршедәге Олы Арташ авылына барып белем алырга туры килә. Болар – 1–9 сыйныфта укучылар. Бакчага 25 сабый йөри. Киләсе уку елында 1 нче сыйныфка 5 бала керәчәк.

Халкы төрле оешмаларда хезмәт куя. «Нырты» авыл хуҗалыгы предприятиесендә 60лап кеше эшли. Авылда мал асраучылар да күп икән. Кемдер читкә чыгып та акча таба. Үзмәшгульләр дә бар. Хатын-кызлар тәм-том пешереп саткалый.

– Җирлегебез кибетләренең берсендә дә аракы, тәмәке сатылмый. Сатучылар әйтүенчә, аннан башка да табыш керә. Бу исә – җирлектә эчүчеләрнең кимүенә бер сәбәп. Аннан заман да, дөньяга караш та үзгәрә бит. Элек һәр башкарган эш хәмергә бәйле булса, хәзер алай түгел. Шөкер, тәртипсез тормыш алып баручылар бөтенләй юк, – ди Алмаз Әгъләмҗанов. – Соңгы 5–6 елда аерылышучылар да юк. Узган ел ике пар гаилә корды. Яшьләр күп. Яшь гаиләләр саны – 20. Ике генә түгел, өч-дүрт бала табучылар да ишәя. Авылда күпбалалы 9 гаилә бар.

Без авылның егетләренә сокланып кайттык. Әтиләр гамьле монда. Алар көчле рухлы, гаиләсе турында кайгыртканда, хатын-кыз бала табарга курыкмый, киләчәге өчен борчылмыйдыр.

Ярату

Регина һәм Айрат Рәхмәтуллиннар ике бала тәрбияли. Регина – Казан кызы. «Авылга кияүгә чыкканына үкенми, шәһәрдә бер көн дә кунмый. Кавышуыбызга – сигез ел. Бакчада тәрбияче булып эшли. Татарча да яхшы белә», – дип мактады Айрат хатынын.

Рәхмәтуллиннар мал-туар асрап көн күрә. Атлары уннан артып киткән. Табыш түгел, күңел хакы өчен торалар.

– Тормышны атлардан башка күз алдына китерә алмыйм. Дөресрәге, сокланып йөрү өчен асрыйбыз. Кызык бит. Кечкенәдән сеңгән инде бу гадәт. Беренче атымны 7 яшь чагында әтиәнидән елап алдырганым хәтердә. Менә шуннан бирле аерылган юк. Аларны колынлатам. Яшәрләр, картаялар… Тормыш шулай дәвам итә. Сораганнарга саткалыйм да, – ди Айрат.

Фәнис Сәлахиев күршеләрен мактап куйды. «Сыерны савасың, ай саен сөт акчасы кертә. Атлар алай түгел. Айрат җәй буе сараена әллә ничәшәр «КамАЗ» печән ташый. Моңа гына да 100 мең сумнан артык акча кирәк. Чыгымына карамый, шуларны зоопарк кебек тота. Күрше-тирә балаларын атка утыртып йөртә. Хатыны да тырыша. Хәзер авыл кызлары да абзарга чыкмый бит», – ди ул.

Бәхет – балаларда

«Шәһәрдә бушлай фатир бирсәләр дә, бармыйм». Монысы – Фәнис Сәлахиевның сүзе. Үз куллары белән зур итеп йорт төзегән ул. Әле шунда музей ачу хыялы да бар. Хатыны белән 4 бала үстерә алар, өчесе – малайлар. Сүз уңаеннан, Фәнис үзе дә биш малайлы гаиләдә үскән.

Сәлахиевлар бик үзенчәлекле гаилә булып чыкты. Ебтылдык үстерәләр. Гаилә башлыгының зоопарк ачу хыялы да юк түгел. Кыр казлары асрый. Тиеннәр алып кайтырга заказ биргән. Тәвә кошлары, күгәрченнәр һәм башкасы да булачак.

Фәнис үзе дә бик авыл җанлы. Иске Икшермә янгын сүндерү бүлеге җитәкчесе ул. Авыл егетләренә: «Авылны саклыйк, бетермик!» – дип кабатлый. «Көчтән килгәнчә, бер-беребезгә булышырга тырышабыз. Берәр нәрсә төзегәндә, өмә ясыйбыз», – ди.

Тормыш иптәше Айгөл фельдшер булып эшли. Авылда сабыйлар мәсьәләсен ул яхшырак белә. Бала көтүче биш ана бар икән. Декрет ялында утыручы әниләр дә күп, диде. Балалар бакчасы гөрләп тора. Димәк, авылның киләчәге өметле. Бәбиле авылда тормыш башкача шул.

«Эчмичә дә яшәп була»

Иске Икшермә янгын сүндерү хезмәтендә эшләүче Фәннүр Җәләлетдинов та шулай ди. Аның әйтүенчә, кибеттә аракының сатылмавы әйбәт. Анда балалар да керә. Күрмәсәләр яхшырак. Егетләр хәмер белән дус түгел, алар үз шөгылен тапкан. «Безнең хобби – мотоциклда йөрү. Унлап егет чыгып китәбез дә рәхәтләнеп ял итеп, көч җыеп кайтабыз», – ди ул.

Фәннүр хатыны Алинә белән өч кыз тәрбияли. Олысы Гүзәлгә – 5, Алсуга – 3, кечесе Сылуга – 6 ай.

– Авылда рәхәт. Казанда биш ел яшәп карадым, әмма күңел авылга тартты. Армиядә хезмәт итеп кайткач, көллияттә төзүче белгечлеген алдым. Аннан читтән торып КХТИны тәмамладым, – ди 31 яшьлек Фәннүр. – Әти-әниебез белән бергә яшибез. Хатыным – Саба кызы. Ул да, авылдан китик, димәде. Мин кайда – ул шунда. Авылда да менә диган итеп яшәп була. Юл бар, интернет кергән. Тамак тук. Тагын ни кирәк?

Фәннүр матурлыкны ярата. Чәчәк сезонында ел саен петунияләр үстереп сата. Быелгысы 3 меңгә җитәчәк. Идея аныкы. Бу эштә хатыны да, әнисе дә булыша. Матурлык дигәнең ишегалдындагы чәчкәләр белән генә бетми. Калайдан бизәкләп, тәрәзә йөзлекләре, коймалар, төзелеш, хуҗалык өчен кирәк-яраклар ясый әле гаилә башлыгы. Яшерми: әлбәттә, бу шөгыльләргә гаиләне акчалы итү өчен алынган.

vk.com

КӨТЕП АЛГАН БӘХЕТ

Бүген Татарстандагы һәр бишенче гаиләдә хатын-кыз табигый юл белән йөккә уза алмый интегә. Республикада гына түгел, ил күләмендә шул ук хәл. Рәсми саннардан күренгәнчә, соңгы ун елда Россиядә бала алып кайта алмаучы хатын-кызлар саны – өч, ир-атлар ике тапкыр арткан. Сабыр канатларын сындырмыйча, нарасыен сөяр көн җитәсенә өмет өзмәгән мондый гаиләләргә замана медицинасы ЭКО (хатын-кызны ясалма орлыкландыру) ысулын тәкъдим итә. Аннан ничек файдаланырга?

Кичектерәсе түгел

Бала алып кайтуны иртәгегә калдырмаска! КФУ Университет клиникасындагы акушерлык бүлегенең 1 нче категорияле акушер-гинекологы Резедә Шәрипова баласызлыкны кисәтүне шуннан башларга кирәк дип саный.

– Әти-әни була алмыйча азапланган парлар артканга аптырый торган түгел. Соңгы елларда карьераны беренче урынга куеп, гаиләле, балалы булуын соңрак кайгырту модага әверелде бит. Ә табигатьне алдап булмый. Яшь барган саен кешенең бала алып кайту сәләте кими бара. Кече оча органнарында ялкынсыну да ешрак күзәтелә башлый. Бу, үз чиратында, шулай ук балага узуга комачаулый. Вакытында сау-сәламәт бала алып кайту өчен хатын-кыз да, ир-ат та җенси юл белән күчүче авырулардан сакланырга, аларны вакытында һәм ахыргача дәвалап бетерергә, даими рәвештә табибка күренеп торырга тиеш, – ди белгеч.

Кыен хәлдә калган парларга ЭКО ысулы ярдәмгә килә. Бүген Татарстанда ЭКОны җиде клиникада ясатып була. Әмма бу хезмәт шактый кыйммәткә төшә. Хаклары 180 мең сумнан башлана. Тик 2013 елдан аны Россиядә яшәүче һәр хатын-кыз бушлай ясата ала. Хөкүмәтнең 2012 елның 22 октябрь карары нигезендә ЭКО мәҗбүри медицина иминиятләштерүе (ОМС) программалары исемлегенә кертелгән. ОМС полисы буенча бушлай ЭКО ясатуга юллама алу өчен бик озак тикшеренергә туры киләчәк. Аның нәтиҗәләре медицина картасында теркәлеп барырга тиеш. Бушлай ЭКО узуга квота алганнан соң, хатын-кыз кайсы клиникада дәваланачагын үзе сайлый ала. Квота нигезендә билгеләнгән акча да шушы оешмага күчереләчәк.

ЭКО турында 2 уйдырма

• ЭКОдан игезәк яки өч игез бала гына туа. Бу программа нигезендә туган балалар арасында игезәкләр дә, өч игез балалар да күп. Тик болай эшләгәндә фәкать игезәкләр генә туа икән дип уйлаучылар ялгыша. Ник дигәндә, һәр илдә хатын-кыз аналыгына кертелгән эмбрионнар санын чикләүче закон бар. Әйтик, Швециядә аналыкка ике генә эмбрион күчерү рөхсәт ителә. Франциядә исә бу сан өчтән артмый. Россиядә дә эмбрионнар саны өчтән артмаска тиеш. Аларның өчесе дә ярылырга яки берсе генә исән калырга мөмкин. Кайбер очракларда өчесе дә «үлә».

• ЭКОдан соң баланы кесарев кисеме белән генә табарга мөмкин. Табигый юл белән йөккә узган хатын-кызның баласын да еш кына операция ярдәмендә алалар. Шуңа ЭКОны кесарев кисемена генә бәйләп карау дөрес түгел. Баланы ни рәвешле табасын табиб үзе билгели.

Өмет өзелми

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, хәзерге вакытта республикада 2,5 мең пар ЭКО ясатырга чират көтә. Үз сәгатең җиткәнче ярты ел – бер ел чамасы көтәргә туры килә, ди белгечләр. Әмма шунысын да истә тотарга кирәк: бу ысул белән әни булырга хыялланган хатын-кызларның 35–40 проценты гына беренче тапкырдан ук йөккә уза икән. Калганнарына исә ЭКО ысулын ике-өч, хәтта дүрт тапкыр да кабатларга туры килә.

Казанда яшәүче 31 яшьлек Алинә Хәсәнова (исем-фамилиясе үзгәртелде. – **Авт.**) да шундыйлардан.

– ЭКО ысулын өч тапкыр кулланып карадык инде – нәтиҗәсе генә юк, – дип башлады ул сүзен. – Өченче тапкырдан да балага уза алмавымның сәбәбен табиблар да төгәл генә аңлата алмый. Икенче ЭКОдан соң ирем белән туры килү-килмәвебезне дә, геннарны да яхшылап тикшерттем. Өченче тапкыр ЭКО ясаткач, йөккә узачакмын дип өметләндем. Мин көткәнчә генә булмады. Болар бит берсе дә бушка эшләнми. Балага уза алмый йөрүемә биш ел була. Соңгы бер ел эчендә ЭКО һәм төрле анализларга якынча 200 мең сум сарыф иттем. ЭКОны бушлай ясату өчен чиратта тагын бер ел торасым бар әле.

Алинә интернеттагы махсус форумнарда үзе кебек язмышка дучар булган хатын-кызлар белән даими аралашып тора икән. «Аларның тарихларын укыйм да күңелдә кабат өмет чаткысы уяна. 6–7 тапкыр ЭКО ясатканнан соң гына йөккә узучылар да бар», – ди ул.

Лениногорск районында яшәүче Марина Князьеваның язмышы да Алинәнекенә охшаш. Тик, аннан аермалы буларак, бүген берсеннән-берсе матур игезәк кыз балалар үстерә ул. «Биш ел балага уза алмый тилмергәч, ЭКО ысулын кулланып карарга булдык. Бәхеткә, беренче тапкырдан ук йөккә уздым. Ике бала анасы булуыма әле бүген дә тулысынча ышанып бетә алмыйм», – ди бәхетле ана.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«ЭКОдан куркырга кирәкми»

Бер тапкыр ЭКО белән әни булган хатын-кыз икенче баласын табигый юл белән алып кайта аламы? Гормональ дарулардан курку урынлымы?

Бу сорауларга Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш репродуктологы Фирая САБИРОВА җавап бирде.

:: Фирая Маратовна, бала алып кайта алмаучылар саны ни сәбәпле арта?

– Кызганыч, әти-әни булу бәхетеннән мәхрүм парлар саны елдан-ел арта бара. Хәзер ил күләмендә аларның саны 15–17 процент тәшкил итә. Үзеннән соң нәсел калдырырга сәләтсез ир-атлар саны хатын-кызларга караганда да күбрәк. Чагыштыру өчен: моннан егерме еллап элек ир-атлар арасында андыйлар саны 15 процент булса, хәзер бу сан 30 процент тәшкил итә. Моңа ир-атның яшәү рәвеше дә, экология, стресс, инфекцияле авырулар да йогынты ясый. Шул ук вакытта хәзерге яшьләр үз сәламәтлегенә игътибарлырак. Элгәрәк баласызлыктан интеккән парлар, мәсьәләнең үзеннән-үзе хәл ителүен көтеп, еллар буе йөрсә, хәзерге яшьләр гаилә корып берничә ай үтүгә йөккә уза алмасалар, шундук табибка мөрәҗәгать итә. Бу бик дөрес. Ник дигәндә, табибка никадәр иртәрәк мөрәҗәгать итсәң, баласызлыкка китергән сәбәпләрне дә шулкадәр тизрәк юкка чыгарырга мөмкин.

:: ЭКОдан куркырга кирәкме?

– ЭКО алымын уйлап табуларына ярты гасыр вакыт узды. Шул вакыт эчендә дөньяда әлеге юл белән 6 миллионнан артык бала дөньяга аваз салган. Шуңа да карамастан, халыкта әле дә булса ЭКОга бәйле уйдырмалар яши. Аңа шикләнеп карыйлар. Пробиркадан туган бала зәгыйфьрәк була, үсеш ягыннан калыша, дигән сүзләрне ишеткәнегез бардыр. Бу сүзләр дөреслеккә туры килми, билгеле. ЭКО ысулы белән туган балаларның яшьтәшләре белән бер үк дәрәҗәдә сәламәт булуы күпсанлы тикшеренүләр нигезендә расланган. Бу балалар башкалардан иркәрәк булуы белән генә аерыла ала *(көлә)*. Шундый катлаулы юл белән бала сөю бәхетенә ирешкән ата-ана сабыйга назын кызганмаячак, билгеле.

:: ЭКО вакытында хатын-кыз гормональ дарулар аркасында симерә, аннары ябыга алмаячак, дигән фикерне дә еш ишетергә туры килә...

– Дөрестән дә, ЭКО вакытында хатын-кызга бик күп гормональ дарулар эчәргә туры килә. Әмма алар табиб билгеләве буенча, тиешле күләмдә генә бирелә. Шуңа күрә хатын-кыз организмына аның бернинди тискәре йогынтысы да юк. Монда икенче мәсьәлә борчу уята. Соңгы елларда ЭКОны олыгаеп кына бала алып кайтырга теләгән хатын-кызлар да күпләп ясата башлады. Андый яшьтә организм таушала башлый, хатын-кыз әле бер, әле икенче авырудан интегә бит. Әни булырга әзерләнгәндә исә алар тагын да көчәергә мөмкин.

:: Беренче баласын ЭКО белән тапкан хатын-кыз икенче баласын табигый юл белән алып кайта аламы?

– Соңгы елларда репродуктив психология дигән күренеш пәйда булды. Белгечләр баласызлыкка китергән психологик сәбәпләрне дә өйрәнә. Беренче тапкыр ЭКО ысулы белән әни булган хатын-кыз еш кына икенче баласын табигый юл белән таба. Ник дигәндә, бер тапкыр әни булгач, аның үз-үзенә ышанычы арта, психологик блок юкка чыга.

ЭКО ярдәмендә йөккә узарга җыенган хатын-кызга киңәшләр

✓ Диета тоту комачауламас. Әни булырга теләүчеләргә туклану рационыннан майлы, кыздырылган, әче, тозлы, ысланган ризыклар белән алкогольле эчемлекләрне сызып атарга туры киләчәк. Артык авырлыктан тилмергән хатын-кызларга йөккә узуы да, корсак күтәрүе дә кыенрак.

✓ Иң элек психик һәм физик талчыгулардан сакланыгыз.

✓ ЭКОга керешергә 1–3 ай кала мунча, саунада парланып утыру киңәш ителми.

✓ Тәмәке тарту да йөккә узу ихтималын киметәчәк.

Хәйретдиновларның гаилә архивыннан

УНБЕР БАЛА ӘНИСЕ:

«БАРЫСЫ ДА МИНЕКЕ»

Алар башта ятимнәргә күчтәнәч илтәләр. Аннары инде үзләрен алып кайталар.

Хәйретдиновлар Казанга Дагыстаннан күченеп кайта. 1995 ел була бу. Ул чакта үз тормышлары да түгәрәк вакыт. Уллары үсеп килә, аңа иптәшкә сеңелкәш тә алып кайтканнар. Бер уйласаң, рәхәтләнеп тыныч кына яшисе дә яшисе генә бит. Тик юк. Ир белән хатын башкача хәл итә. Алар, җәйләре чыгуга, ятим балаларны сөендерергә ашыга.

– Без яшәгән йорттан ерак түгел ятимнәр йорты бар иде. Башта болай гына барып кайттык. Аннары күчтәнәч төяп киттек. Андагы сабыйларны күреп йөрәк әрнеде. Җитмәсә, авыру сабыйлар бит әле алар, – дип искә ала Лилия.

Ире белән киңәшләшеп, алар башта бер баланы бәхетле итмәкче булалар. Ятимнәр йортында аларга бер малай күрсәтәләр. Ул исә сау-сәламәт, матур, аягында нык тора. Шунда Лилия бу баладан баш тарта. Аны башка әти-әниләр аласына ышана. Үзләренә ярдәмгә мохтаҗ, авыру бала күрсәтүләрен сорый. Аларга берне түгел, дүртне алып чыгалар. Дүртесен дә алып кайтып китәләр.

– Ул чакта улым да, кызым да безнең белән яшәми иде инде. Ә өебез зур. Нишләп утырыйк әле, диештек тә сабыйларны әти-әниле иттек. Без алмасак, ул авыру балаларны берәү дә сайламас иде. Әгәр миннән торса, физик мөмкинлеге чикләнгән һәр сабыйны гаиләле итәр идем. Аларның алдагы көннәрен уйлыйм мин. Үз-үзләрен йөртә алмыйлар, сәламәтлекләре әйбәт түгел, гел ярдәм кирәк. Әнә шуңа да гомерләрен кешечә үткәрүләрен телим.

Бераздан бу гаилә, ишле балаларны тагын да зуррак йортта яшәтәсе килеп, Арчага күченә. Биредә барысына да күз-колак була аласың. Түгәрәкләргә йөртәсең, эшкә өйрәтәсең. Ни генә булса да, әниләре гел янәшә. Лилия бу малайларны ничек бар шулай ярата. Беренчедән, үзенеке итеп сөя ала, икенчедән, кимчелекләрен күрми. Лилиянең йөрәге бик зур аның. Сөйләшкәндә гел бер сүзне кабатлый: «Безне мактый гына күрмәгез». Ә бит мактарлык та үзләрен. Дүрт бала янына тагын бишне сыендыра алар. Ә инде иң авыр хәлдәге баланы язмыш тагын да кимсетә күрмәсен дип, үзләренеке итәләр. Исем-фамилияләрен биреп, уллыкка рәсмиләштерәләр. Барысы да бала язмышы өчен эшләнә. Лилия улы белән кызына да Юраны ташламаска дип әйтеп куя.

21 яшьлек Данила, үзенчә яшим дип, бу гаиләдән китеп тора. Тик, кызганыч, ахыры хәерле булмый. Җыелган акчаларын таратып бетергәч, инвалидлыгыннан колак каккач, Данила гафу үтенеп кайтып керә. Гаилә аны кабул итә. Урамда калдыра алмыйлар бит инде.

– Тәрбиягә алган балаларны үз әти-әниләренең эзләп килгәне булмады. Хәер, акылга зәгыйфь балалар кемгә кирәк булсын инде? Аларны ярату өчен, зур йөрәгең булу гына җитми әле. Сабырлык та, нык сәламәтлек тә кирәк. Шөкер, сабыйларым сүземне тыңлый торган булдылар. Кайчак хаталанулар да кирәк. Алайса, ак белән караны да аера белми калырлар иде, – ди Лилия.

Баштарак Лилиянең авыру балалар алуын аңлап бетермәүчеләр дә табыла. Төрле сүзләр дә ишеттерәләр. Әмма балаларны үз канаты астына аласы килгән гаиләне бу туктатмый.

– Балалар өчен 10 мең сумга якын акча бирелә. Безнекеләрне гел дәваларга кирәк. Кайберләренә операцияләр ясаттык, – ди Лилия. – Ул балалар – үзе бер дөнья. Иң мөһиме – мин аларны, алар мине ярата. Минем өчен алардан да яхшы бала юк. Ятимнәрне тәрбияләүне зур эшкә санамыйм. Күңелем кушканны башкарам. Миңа шулай рәхәт. Әгәр тагын бер кат яшисең дисәләр дә, шушы язмышымны кабатлар идем.

ХИКМӘТ БУЙДА ТҮГЕЛ

120 СМ БУЙЛЫ НИКОЛАЙГА ЙӨРӘК ЗУРЛЫГЫ МӨҺИМРӘК

Кечкенә дә төш кенә! Николай кебекләр турында шулай диләр. Тормышта буй түгел, рух ныклыгы мөһимрәк. Кукмара районының Пчеловод авылында гомер итүче Николай Сергеевны социаль челтәрләрдә күреп алдым мин.

Вахит авылы җирлегендә оештырылган концертта чыгыш ясый иде. Тамашачы да ярата үзен. Сәхнә буйлап бер әйләнеп чыгуы җитә, дәррәү кул чаба башлыйлар. Хикмәт нидә соң? Бу кеше белән танышасым килде. Кечкенә буйлы Николайны табу кыен булмады.


kukmor-rt.ru

– Алты балалы гаиләдә үстем мин. Әти белән әни дә, калган туганнарым да – гадәти кешеләр. Ә менә миңа Ходай буйны бирмәгән инде, – дип сөйли башлады ул. – Биш яшемдә ат арбасы астында да калдым. Анда да табибка күрсәтеп тормадылар, ахры, мине. Кабыргаларым сынган иде. Умрау сөягем, ике кулым имгәнде. Чүпрәккә төреп бәйләп куйганнарын гына беләм. Бик озак вакыттан соң кире сүттеләр. Әллә шунда имгәнеп, үсми торган булып калганмын инде, белгән юк. Табиблар да дәва тапмады. Мин үземнең кечкенә буйлы икәнемне үсми башлагач кына аңладым.

Николай абыйга тиздән 70 яшь тула. «Кешегә яшьне әйтеп сөйләшкәнем юк иде», – ди ул. Бу юлы инде юбилее җиткән хөрмәткәмә, яшереп тормады.

– Буең күпме дисеңме, сеңлем? Бик кечкенә инде мин. Элек 124 сантиметр идем, хәзер инде 120гә калдым. Әмма шулай да зарланмыйм. Тормыш итү өчен буйның озынлыгы кирәкми дә икән. Янында яхшы кешеләр булса, син үзеңнең кимчелегеңне сизмисең дә, – ди Николай абый. – Әти-әнием дә, туганнарым да мине кимчелегем белән бергә яраттылар. Кызганыч, ике туганым арабызда юк инде. Олы апам белән абыем вафат булдылар. Өч апам белән мин генә калдым.

Николай абый башлангычта авыл мәктәбендә укый. Бишенчегә барганда, әти-әнисе аны Шәмәрдәнгә күчерә. Янәсе, русча укырга өйрәнсен, диләр. Татарча гына сөйләшеп үскән бала беренче елны берни аңламый утыра. Соңрак русча өйрәнә. Янындагы дуслары да булыша. Сыйныфташларына бүген дә рәхмәт укый Николай абый. Үзләре дә бер сүз әйтми, башкалардан да кимсеттермиләр аны. Николай турында бер кыек сүз ишетелсә, дәррәү яклап чыгалар. «Гомеремнең иң рәхәт чаклары Шәмәрдәндә үтте», – ди ул.

– Мәктәпне бетергәч, Лаеш авыл хуҗалыгы техникумына укырга кердем. Мине район җибәргән иде. Укып бетереп, тиешле елымны эшләдем дә, хисапчы һөнәре минеке түгел икән, дигән фикергә килдем. Әни күп уйлап тормады, мине Казанга алып чыгып китте. Яңадан укырга кердем. Бу юлы сәгать төзәтергә укып чыктым. Менә монысы минем эш иде инде. Бер дәрестә безгә өстәл өстендә тора торган сәгать тараттылар. Мин аны сүтәсе дип белдем. Алдым да сүттем. Укытучы бик яратып бетермәде. Башкалар төшке аш ашаганда, 45 минут эчендә кире җыеп куйдым. Теге укытучы шаккатты инде. «Бишле»сен кызганмады. Уку йортын кызыл дипломга тәмамладым.

Укып бетергәч, Сабага кайтып эшкә урнаша. Бер ел эшләгәч, әти-әнисе улларына машина алып бирә. Шуннан соң Николай көн дә өенә кайтып йөри. 16 ел сәгать төзәтә ул. Хәзер инде бу эш бетте дип уфтана. Ә бит заманында көненә әллә ничәшәр сәгать төзәткән ул. Санап бармадым шул, меңләгән инде алар, ди.

– Ышанасызмы, юкмы, 19 ел машина йөртү таныклыгы булмаган килеш рульдә йөрдем. Казанга барсам, Биектауда машинаны калдыра идем. Чаллыга барсам, автовокзал тирәсенә куеп торам. Кукмара, Балтач, Сабада миңа бәйләнүче булмады. Туктатмыйлар да иде. Ул чакта таныклык алу өчен буйның 150 сантимер булуы кирәк иде бит, шунлыктан ала алмадым инде. Соңрак таләпләр үзгәрде. Кешенең игътибарына, тизлегенә карый башладылар. Мин дә таныклыклы булдым, – ди ул.

Николай абый уникенче машинасын алыштырган инде. Соңгылары автомат коробкалы, алары бик уңай икән. Ә менә аяклар кечкенә булгач, педальләрне күтәртеп озынайтканнар.

– Машинада йөрү ярты бәхет инде. Кая барасың килә, утырасың да чыгып китәсең. Мин гаилә кора алмадым. Мария исемле апам белән яшим. Икәү булгач, тормыш итү җиңел. Йөри торгач, хондродистрофия диагнозы куйганнар иде миңа. Шуның аркасында 45 яшемдә пенсиягә чыктым. Пенсия генә көтеп ятмыйбыз, күп итеп маллар тотабыз. Үгезләребез бар, күп итеп тавык-чебешләр, казлар асрыйбыз. Аларны сатабыз, – ди Николай. – Тырышырга кирәк. Тик утырсаң, китереп бирмиләр. Булдыра алмаган эшкә тотынмаска кирәк. Алай эшләп, үзеңне бетерәсең генә. Минем кебекләргә сүзем шул: кеше арасына чыгыгыз. Аралаша торган эш табыгыз. Буй кечкенә булу берни түгел, йөрәгең зур булсын.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РЕНАТ ӘЮПОВ:

«ТЕАТР ЭГОИСТЛАР УРЫНЫ ТҮГЕЛ»

Яшьләргә театр сәнгате ни дәрәҗәдә кызыклы? Аларны җәлеп итү өчен үзгәрергә кирәкме? Театрда нинди уңай, нинди тискәре күренешләр бар? Болар хакында Габдулла Кариев исемендәге яшь тамашачы театры баш режиссеры Ренат ӘЮПОВ белән сөйләштек.



kariewteatr.ru

:: Бүгенге яшь тамашачы нинди ул?
– Ул таләпчән, игътибарын яулап алу һәм югалтмау өчен шактый тырышырга мәҗбүр итә. Әйтик, беренче биш минутта аңа спектакль ошамый, кызыксыну тудырмый икән, ул кулдан ычкына. Бу инде – спектакль бетте дигән сүз. Бүгенге тамашачы әнә шундый. Чөнки аны боза торган факторлар шактый. Бу – гаджетлар, интернет, социаль челтәрләр, үзләренең чатлары-төркемнәре. Яшьләр шунда яши. Театр интеллектуаль, ягъни уйларга мәҗбүр итә торган товар тәкъдим итә. Ә хәзерге буын уйларга да ялкаулана, карап утырырга да яратмый. Бу буын игътибарын виртуаль-визуаль бизәлеш, даими хәрәкәт, шаккатыргыч алымнар белән җәлеп итеп була. Нишлисең, заманасы нинди – тамашачы да шундый.

> Театр үзгәрми. Аның нигезе нык. Без бит кеше язмышы, фаҗигасе турында сөйләшәбез, психологиясен ачабыз. Димәк, нигез беркайчан да үзгәрмәячәк. Ә менә алымнар, стиль, формат үзгәрә. Аннан башка булмый.

:: Хәзерге заман театрын алсак, нинди уңай һәм нинди тискәре күренешләрне аерып әйтер идегез?
– «Перфоманс» дигән форма килеп керде. Мин аны театр сәнгате тамырына кизәнгән балта дип саныйм. Перфоманста актерлар, җансыз объектка әйләнеп, психоз халәтендә яши. Бу очракта тән хәрәкәте алга чыга, ә театрның нигезе булган туган тел, драматургия, актерлык осталыгы һәм кичерешләрне мул итеп бирү юкка чыга. Хәзер лабораторияләр популяр. Әмма аларның күбесе актерлык осталыгын боза торган юнәлештә. Нәтиҗәдә төрле режиссерлар төрле алымнар кертеп, актерның сәхнәдә яшәвен, узаңын үзгәртә. Ул аптырап, тукталып кала. Тагын «вербатим» дигән жанр популярлашып бара. Мин аны уңай бәялим. Чөнки безнең театр психологик уенга нигезләнгән. Бу жанрда актерга эчке кичерешләрне читкә этәреп, алар хакында сөйләп бирергә кирәк. Бу актерга уйларга, күзәтергә мөмкинлек бирә. Эскизлар алымы бар. Әйтик, «Тамга» лабораториясендә авторның идеясен ачарга мөмкинлек бирелә. Монда автор, режиссер, актер бергәләп эшли, шулай итеп булачак спектакльгә күпер салына. Менә шундый, режиссерны да, артистны да үстерә торган алымнар, формалар бик кирәк.

:: Сез кайбер пьесаларга берничә тапкыр алынасыз. Бу – яңа пьесаларга кытлык дигән сүзме?
– Хәзерге заман драматургиясе, кызганыч, бик аксый. Сәбәбе бик гади: драматурглар аз. Татарстанның 13 дәүләт театры бар, алар бер сезонда уртача 3–4 премьера чыгарырга тиеш. Күпме яңа пьеса кирәк дигән сүз бит бу. Батып баручы саламга ябышса, режиссерлар классик әсәрләргә, прозага алына. Әмма прозадан сценарий язучы яхшы сценаристлар да юк дәрәҗәсендә. Туфан Миңнуллинның мәктәбе, әсәрләре калды, әмма артыннан аның эшен дәвам иттерүче көчле драматурглар үсеп чыкмады. Нәтиҗәдә театрлар лабораторияләргә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр. Кайвакыт ул яхшы гына нәтиҗә бирә, ә кайчак тискәре нәтиҗәләргә китерә. Һәр театр бу җитешсезлекләрне үзе бетерергә тырыша. Ул драматурглар да, сценаристлар да әзерләп карый, конкурслар да игълан итә. Әмма бу системалы эш түгел, шуңа күрә нәтиҗәсе бик аз.

:: Ә яңа татар драматургиясе бәйгесе?
– Ул даими рәвештә алып барыла. Мин – анда жюри әгъзасы да. Әмма анда килеп чыккан драматургларны кызыксындыру, финанс ягы түбән дәрәҗәдә. Бәлкем шуңа күрә катнашучылары да – шул ук бер кешеләрдер.

:: Яшьләр театры үткән юл сезне нығыттымы?
– Без 6–7 ел элек кенә өйле булдык, аңа кадәр чегәннәр тормышы белән яшәдек. Башта бинабыз булмады, анары Алафузов театры бинасына кердек. Ул авария хәлендә булганга, анда да озак эшли алмадык. Аннан курчак театрының концерт залына кердек, рус ТЮЗының ат абзарында да эшләп карадык. Өйсез яшәдек, әмма артистларны һәм репертуарны саклап кала алдык. Әйе, алдыбыздагы киртәләр безне нығытты гына. Хәзерге йортыбыз ул – кинотеатр өчен корылган бина. Әмма түбәле булу репертуарны саклау һәм үсеш өчен бик кирәк.

:: Сезнең өчен театр ул – ...
– коллектив хезмәт, тулы бер ансамбль сәнгате. Ул эгоистлар урыны түгел. Монда бер кеше – юк кеше. Монда бергә җыелып, теманы уртага салып сөйләшеп, аңлашып кына иҗади продукт тудырып була. Шулай булса гына спектакль һәр кешегә үз баласы кебек якын һәм кадерле була. Театр – бергә җыелган хезмәткәрләрнең дивана эше.

:: Яшьләр театрын яшьлек театры дип кабул итәсе килә. Сездә яшь актерларга кытлык бармы?
– Андый кытлык юк. Мин һәр буынны күзәтәм һәм кайда нинди кимлек бар – тулыландырырга тырышам. Бездә барысы да үз урынында: олы буын да, урта буын да, яшьләр дә. Репертуарны тупларга һәр буын кирәк. Олы буынны, урта буынны саклыйм, яшьләрне тулыландырып торам. Һәр сезон саен актер алмыйбыз, билгеле, әмма бер-ике яшь артист театрга даими килә. Быел 4 актер кабул иттек. Алар әле дә сынау вакытын уза. Дөрес, актерның бу театр кешесеме-юкмы икәнен бер айда ук чамалап була. Битараф, ялкау булмаса, ул кеше безнеке.

:: «Өлкән буынны саклыйм» дигән сүзегез ошады әле. Чөнки ул бүгенге заманга каршы килә. Күп җирләрдә, эшлисен эшләгән бит инде, театр карт актерлар өчен түгел, дигән сүзләр ишетелә.
– Театрга гомерен, сәламәтлеген биргән, шушы театрның пионерлары булган шәхесләр белән саубуллашуны мин хәтта җинаять дип саныйм. Бу – театр җитәкчеләре, баш режиссерлары, шушы хәлгә юл куйган башка актерларның бик зур гаебе. Олы буын артистлары нинди генә халәттә булмасын – аларны сакларга кирәк. Йорт салган кеше белә: нигездән бер генә кирпечне тартып ал – ул ишеләчәк. Монда да шул ук күренеш. Олы буыннан баш тарткан театрлар үзүзләрен җимерү юлына баскан. Бик кызганыч бу. Бездә андый хәлнең булганы юк.

:: Үткәннәргә борылып карасак, Камал театры актеры, яшьләр театры режиссеры, Чаллы театры режиссеры булгансыз. Кайсы чор күбрәк сагындыра?
– Мөгаен, Камал театрында эшләгән вакыт сагындыра дигән җавап көтәсездер. Әмма мин Чаллыда эшләгән вакытларымны сагынып искә алам. Мин анда 7 сезон эшләдем. Шәһәрнең мохите башка, энергетикасы икенче, тамашачы да бик актив иде. Бу театрның артистлары миңа баш-аягы белән ышанды, һәр спектакльнең автордашы булды. Хәзер инде андый нәрсә бетте, эгоистлык алга чыкты. Чаллыда мин классик әсәрләрдән алып балалар спектакленә кадәр куйдым, кызыклы тәҗрибәләр дә ясап карадык. Чаллы тамашачысы хезмәтемнең көзгесе булды. Һәм беркем дә бу көзгегә төкереп китмәде, киресенчә, аларга кызык иде. Нәтиҗәдә кызыклы репертуар туды. Анда кулланган алымнар белән мин, мәсәлән, Камал театрында эшли алмас идем. Ул «замашка»ларны кабул итмәсләр иде. Бирелдәге яшьләр яратты, үз кешесе итеп кабул итте һәм бу чор иҗат трамплины булып истә калды.

:: «Актер буларак әрәм булды» дигән сүзне еш ишетәсезме?
– Юк, алай әйтмиләр. Әйе, мин – щепкинчыларның икенче буыны вәкиле. Камал театрына эшкә алдылар, әмма нишләптер башта ук: «Бу театр тулы бит инде, монда безгә урын булырмы икән?» – дип уйлап куйган идем. Безнең иләс-миләс йөргәнне театр директоры Шамил Закиров сизеп алды да Дамир Сираҗиевка: «Бу яшьләргә яңа әсәр кирәк», – дип әйтте. Дамир озак уйлап тормады, поляк язучысы Кшиштов Хоинскийның «Төнге кунак»

дигән пьесасын куйды. Бу 1990 нчы еллар, Казан феномены, урам белән урам бәрелешкән вакытлар иде. Пьеса да нәкъ шул ук тема хакында булып чыкты. Анда мин төп герой Марикны уйнадым. Бу бик зур мәктәп булды. Камал театрында рольләр өеп бирелмәсә дә, Сираҗиев, Марсель абый Сәлимҗанов спектакльләрендә уйнадым. Менә шул вакытта миндә режиссура белән кызыксыну уянды. Сираҗиевның «ассистенты» булдым, Марсель абый спектакльләренә актер итеп алмаса да, аның репетицияләрен балконнан карап утыра идем. Нәтиҗәдә кече залда үзем спектакльләр куя башладым. Нәкый Исәнбәтнең «Былтыр кысты» дигән әсәрен сәхнәләштердем. Мөгаен, менә шушы әсәр миңа Яшьләр театрына кайтуга сәбәп булгандыр. Чөнки бернәрсә дә очраклы була алмый. Аннан Марсель абый башка спектакльләр куярга рөхсәт бирде.

> Шамил Закиров, Марсель Сәлимҗанов зур шәхесләр иде. Аларның җиңел кулы белән күпме режиссер, драматурглар дөньяга чыкты. Марсель абыйның: «Зур корабта эшләү бик яхшы, әмма һәр кешегә үз көймәсе кирәк», – дияе дә истә. Яшьләр театры минем көймәм булды һәм хәзер инде корабка әверелде.

:: Театр торгынлыктамы?

– Бу фикер белән килешмим. Театр ул – тере процесс, ул яши, үзгәрешләр кичерә, ул тукталмаган. Әмма уңышсыз сезоннар була. Тамашачысын таба алмаган спектакльләр була. Бу уңышсызлык кызыклы спектакль тудыруга этәргеч ясый.

:: Өстәл китабыгыз нинди?

– Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре. Аны өч тапкыр сәхнәләштерүем дә юкка түгел, чөнки бу әсәрдә нинди генә тема юк! Авыр чакта шушы әсәрне кулыңа алсаң: «Кара әле, моңа бит үткән гасырларда ук җавап табылган!» – дип хәйран каласың.

:: Татар режиссерының төп сыйфатлары нинди?

– Татар әдәбиятына гашыйк булу, һәр яктан да укымышлы булу, телне, камил булмаса да, белү, тормышында татар телен өстенлекле итү, традицияләрне саклау, артистка бәйле икәнлегеңне аңлау, артистларны ихтирам итү, аларның үзеңнең автордашың итү, үзеңне түгел, актерны алгы планга чыгару, лидер булу.

:: Гаиләгезгә вакыт каламы?

– Бу очракта кайда гаилә, кайда театр икәнен аерып та булмый. Алар кушылып бетте инде. Яшьләргә спектакль чыгарганда 14 яшьлек улым Нурлан белән киңәшәм. Ул кайда ялган, кайда мантыйк өзелгән – шунда ук сизә һәм яшьләргә кызык булмаслык моментлар турында кисәтә. Аннары инде хатыным Гөлшат цензурасын да узабыз. Аны кызыксындыргангабыз икән, димәк, спектакль бар. Гаиләгә театр вирусы кергән һәм без аның белән яшибез инде. Театр негатив буларак кабул ителми, киресенчә, ул дуслаштыра гына. Гаиләм ул – минем тылым да, автордашым да. Театр юлыннан бергә атлыйбыз.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

(ХИКӘЯ)

ЛИЛИЯ ФӘТТАХОВА

ТӘРӘЗӘЛӘР

Нәҗия әби тәрәзә араларына чүпрәк-чапрак кыстырып йөри. Үзе тып-тыныч тавыш белән сөйләнә:

– И-и, карт кешенең җүне юк шул инде аның. Җүне булса, эш эшләтерләр иде карт кешедән.

Менә икенче көн инде аның белән икәүләп кинәт кенә суык белән куырырга керешкән көннәргә яраклашып яткан мәлебез. Тышта термометр утыздан артыкны күрсәтә. Өстәвенә төньяктан искән җил җелегеңә үтә.

– Әле дә ярый, утын ярып, мич ягасы түгел, Алланың рәхмәте. Андый вакытлар да бар иде бит.

Әбинең өстендә сырган бишмәт, аягында киез итек, башында җылы шәлъяулык. Мин дә шул чамарак киенгән. Бишмәт урынына йон свитер өстеннән әбекәйнең калын йон кофтасын киеп алдым, аягыма да оекбаш өстеннән иске киез итеген кидерде әбекәй. Җылы сөяк сындырмый!

Кышкы урманга агач егарга барырга җыенган утынчылар сыман киенеп куйсак та, тирләтми үзе. Әбекәй көз көне генә тәрәзәләрен юып алган да, эчке катын ныгытып ябарга оныткан. Инде менә исенә дә төште дә бит, узган эшкә салават шул инде: байтак тәрәзәләр эчтән ябылып бетми. Йодрык сыярлык булып авызларын ачкан тәрәзә аралары әбине үртәгән сыман салкын һава өреп утыра.

– Карт кешенең җүне юк шул, җүне юк... Җылы юк... җылы юк...

Әбинең үзе белән бергә картаеп килгән өенең дә яше бар – ниргәләрдән салкын керә. Кеше генә түгел, өй дә туза-туза җылы тотмый башлый икән шул.

Шулай да идәннәрне юып чыгарып, келәмнәр җәеп куйгач, бераз гына ямьләнеп, җылынып китте бугай әле үзе.

Сиксән җиденче яшен ваклаган әбекәй гомере буе колхоз эшендә эшләгән. Тегермәнче ир иртәдән кичкә кадәр тегермәнендә яткан, ирләр эше дә әбекәйгә йөкләнеп калган. Өйне пакьләп-арулап торырга әллә ни вакыты калмаган аның. Мин кунак кеше булгач, идән юуыма да теше-тырнагы белән каршы иде ул:

– Үткән атнада гына көрәп чыккан идем әле, ярамаган инде карчык кешегә...

Әкияттәге убырлы карчык кебек гел киресен сөйләсә дә, өй матурланып киткәч, сөенде үзе.

Әбекәйнең өч баласы да калада. Ана күңеле – балада, бала күңеле – калада... Сирәк кайта алар. Бердәнбер кызы тәрәзәләрне кайтып юар дип көтә-көтә, җәй дә узган, көз дә кергән. Инде менә зәмһәрир суыклары белән кыш тантана итә.

– Бигрәкләр дә эш ярата идем инде яшь чакта. Бәрәңге утыртабыз бит инде, име, нишләп шулай тиз бетте соң бу, дип уфтана идем.

– Алай булмыйдыр инде, Нәҗия әби.

Үзем ул бәрәңге утырту, алу эшләрен яратып бетермәгәч, әбинең сүзләре минем өчен аңлашылып бетми.

– Шулай да була икән шул ул, балам. Әкартайгач, эш юк икән бит ул, вакыт күп икән. Вәт, агай, ә! Эш биргәндә эшләп калыгыз сез, эшләп калыгыз. Картайгач, эш бирмиләр икән бит ул.

Нәҗия әби газ торбаларына кулын тидереп алды.

– Кайнар үзләре, Алланың рәхмәте. Төн җиле суыра җылыны, төн җиле – төн җиле шул ул.

Мин дә берничә тәрәзәгә «ашыгыч ярдәм» күрсәттем дә эшебезне фотога төшереп алдым.

– Нәҗия әби, салкын дип әйттеңме соң балаларыңа? Тәрәзәләреңне малайларың кайтып, әйбәтрәк итеп яба алмаслар идеме икән?

– Юк, әйтмәдем. Кайткач күрерләр әле.

– Соң, әллә кайчан кайта әле алар? Олысы шалтыратмый да, дисең.

– Юк, ялгышып та шалтыратмый. Минекен дә алмый әле ул. Кайткач, нигә бер дә шалтыратмыйсың соң, дисәм, «әй» дип кенә куя. Анысы бөтенләй дә сүзгә саран аның.

– Кичесе көн дә телефоннан хәл белешеп тора, дисең бит, аңа әйт инде булмаса.

Мин җөмләмне тәмамларга да өлгермәдем, әбекәйнең кесә телефоны ниндидер көй уйный башлады. Берәрсе шалтыратыр да ишетми калырмын дип куркып, телефонын гел кесәдә йөртә ул.

– Ә-ә, әйбәт, улым. Әйбәт. Менә кунагым бар әле. Бәйрәм әле бүген миндә. Әйбәт, әйбәт. Шикәрем дә әйбәттер әле, улчәгәнем юк, әйбәттер кебек тоела. Кан басымым да әйбәт әле. Менә кунагым бар бит әле, шуңа шатланып утырам. Үзегез ни хәлләрдә, улым? Ярар, әйбәт булсын инде.

Җылымы дип, бишмәт кисәң, җылы үзе, өшетми. Тәрәзәләр бигүк ябылып бетми, берәр кайтканда карарсыз әле дип торам. Үзем тотынсам ватармын кебек. Әле кайтмыйсызмы соң? Айдан арты бит инде. Ярар-ярар, үз җаегызга карагыз инде. Кайтыгыз дип тә әйтмим, кайтмагыз дип тә әйтмим. Җаегызга карагыз. Болай әйбәт әле хәлләр, Аллага шөкер. Ярар, улым, хәлләремне беләсең, онытмыйсың, рәхмәт.

Нәҗия әби телефонын кесәсенә саласы итте дә, инде бүген башка шалтыратучы булмас дип уйлапмы, өстәл өстенә куйды. Аның йөзе һәрвакыт тыныч: борчыламы ул, шатланамы – тиз генә белеп тә булмый.

– Кайтыгыз дип тә әйтмим, кайтмагыз дип тә әйтмим, кайтмасагыз кайтмагыз инде, – диде ул, ишек катына атлап. Кулына баярак әзерләп куйган савытны алды. Лапаста аны җиде мәче көтә. Җәйгелеккә генә кайтып торучы күршеләре үзләре китә дә, ач мәчеләр барысы да йомшак күңелле әбинең лапасына җыелып бетә. Үзе киенә, үзе сукрана әби:

– Мур кыргырлары! Үлмисез дә бит ичмасам. Ничек ашатып бетерим мин сезне?

Шулай дисә дә, көнөнә дүртәр тапкыр коштабагын күтәреп әйләнеп керә ул мәчеләр тирәсеннән. Әле тагын егермеләп тавыгы бар, аларны да бик хасиятләп карый.

Нәҗия әби чыгып китүгә, аның телефонынннан соңгы номерны карап, шул номерга «Ватсап» аша фотолар юлладым. Ябылып бетмәгән тәрәзәләр, бишмәт киеп, бөкрәеп утырган әбекәйне улына күрсәтәсем килде. Пошынмый гына атмагыз әле, имеш, әнкәгез бит ул!

«Нәҗия әбигә суык бит, егетләр. Саулыгы да бу көннәрдә әллә кем түгел, сезгә генә зарланасы килми аның. Бәлки, кайтып әйләнерсез? Бигрәк ямансулый бит». Фотолар артыннан ук шундый хатым да «очты».

Аннары, бераз уйланып торганнан соң, тагын берничә җөмлә язып куйдым: «Газ буенча килешүләрне яңартасы, диләр. Өй үз исемендә булмагач, аңа да бик борчыла әниегез».

Смсларны тиз укыды «Вахит улым». Шундук җавап язып та җибәрде: «Үземнең классташ (укытучы ул) сорый миннән. СССРны торгызабыз, законнарны дөреслибез, дип йөргән буласыз, нәрсәгә ирештегез соң, ди. Сез сионистлар үрчетеп ятканда, без халыкны агартабыз, сезнең кебекләр булмаса, халык сарык кебек өстән төшкән бөтен документка уйламыйча кул куймас иде, дидем. Сезгә юан колбаса, безгә дөреслек кирәк, дидем».

Мин смсны кат-кат укыдым, һичнн аңлый алмадым. Нинди юан колбаса? Нинди СССР? Ни яза бу кеше? Мин бит аңа әнисе турында гына яздым. Миңа җавап бирдеме соң ул, әллә ялгыш язып җибәрдеме?

«Аңламадым». Җавабым бер сүзле генә иде.

Күп тә үтмәде, «Вахит улым» миңа интернеттагы бер видеога сылтама җибәрде. Ачтым. Анда бер төркем хатынкыз, газ идарәсенә килеп, шау-шу куптарып яталар. «Сез – Эрефия дигән оешманың ялчылары. Халык акчаларын Америкага җибәреп ятасыз. Без – җирле үзидарә вәкилләре, без сезгә буйсынмыйбыз...»

Сәгать ярымлык ул видеоны бераз карадым да ябып куйдым. Аңлашылды, Нәҗия әбинең улы минем соңгы соравыма җавап җибәргән икән.

«Утопия түгелме бу?» – соравым тегеякка китте.

Берничә секундтан ук җавап та килде: «Колбасагыз симез булсын!»

Әтекәчкенәм икән! Миңа да эләкте.

Башта көләсе килде. Аннары кайнар каным йөрәгемне ярсытып алды; ул күкрәк читлегенә дөп-дөп кагып, бераз ризасызлыгын белдереп торды да тынычланды.

«Илдә гаделлек урнаштырам дип буш идеяләр белән вакыт уздырганчы, әниегезнең хәлен белеп килергә вакыт тапмассыз микән? Кулдан килмәгәнгә үрелгәнче, кулдан килгәнне эшләсәгез иде!»

Усал итеп язылган смсымны җибәрергә дип үрелгән кулым ярты юлда туктапып калды. Икебез ике туннельдә бит без, дип пышылдады акыл. Язганнарымны бетереп аттым да телефонымны әбинеке янына куйдым.

Өй ишеге ачылды. Аннан ажгырып кергән суык һаваны алга үткәреп, ярты-лаш бөкрәйгән Нәҗия әби атлады.

– Җан ияләре бит инде. Алар да яшәргә маташа, күрәләтә ничек үтерәсең. Берәү генә булса, өйгә дә кертер идең дә бит, бигрәк күпләр шул. Ул кадәр мәчене өйдә асрарга йөрәгем җитми.

Әбекәй бушап калган савытын чәйкап куйды. Бирчәеп беткән кулларын кайнар торбага куеп, бераз җылытты да:

– Әй, кеше кулына калма икән ул, – дип көрсенде.



Сканворд җаваплары

Горизонталь: ария, сипкел, тач, Алканат, ру, сакалы, Рәсим, Алия, Камил, урын, самурай, Клаус, абау, кургаш, асрама, Күки, Луи, лайк, Глоба, Урмай, клелия, ЗиС, мач, Асаев, Рио, Быклар, ПКМ, Явыз, Камал, абыстай, Радий, Илон, Ор, Миләүшә.

Вертикаль: басма, Ла, Сарман, Тимур, мал, яу, алачык, Рамай, Ка, алабай, алма, Рим, битлек, йа, Сааб, Али, Пак, ак, ук, карлы, Дол, акчарлак, үчле, инә, ре, ымлык, Евпатий, Илдар, Иа, Игл, Ош, турлук, Ли, Мәйсәрә, Сукояр, су, ияр, ир, Глазов, Мырау, ым, шиксез.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә...

1 **Бу илдә халык саны Россиянекеннән 1,5 тапкыр күбрәк:**
а) Алжир;
б) Нигерия;
в) Мисыр.

2 **Александр Лукашенко Казанга килгәч, Рөстәм Миңнехановка нәрсә бүләк итте?**
а) картина;
б) келәм;
в) каләм.

3 **Фуа-гра ризыгын әзерләү өчен нәрсә кирәк?**
а) балык;
б) елан;
в) үрдәк.

4 **Казанның Качалов театрына быел ничә ел була?**
а) 222;
б) 233;
в) 323.

Җаваплар: 1.б); 2.в); 3.в); 4.б).

Әз-мәз мәзәк

– Соңгы тапкыр сорыйм! Акчаны кайчан кайтарасың?
– Ой, рәхмәт! Бу соравың инде туйдырган иде.

***

– Фәнил! Ник эштә түгел син?
– Гафу итегез, Гали Вәлиевич, ничектер башымнан чыгып очкан, бөтенләй онытканмын.

***

Нейрочелтәрләр кар көрәр, ә кешеләр иҗат белән генә шөгыльләнер дип уйлаган идек. Киресенчә килеп чыкты: нейрочелтәрләр иҗат белән шөгыльләнә, ә кешеләр кар көри.

***

– Йә, кызларым, нәрсә алып кайтыйм сезгә ерак илләрдән?
– Бәтәч, ә без бармыйбызмыни?

***

Моның нинди зур проблема китереп чыгарасы турында укыгач, бу турыда укуымны ташладым.

***

– Сиңа күпме яхшылык эшләдем, тиз онытасың шул.
– Мәсәлән, нинди яхшылык инде ул?
– Хәзер генә искә дә төшми инде.

***

Бик тә экономияле кияү белән кәләш, видеооператор яллап тормас өчен, туйларын тырышбрак истә калдырганнар.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 11293 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 230

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+